Зифа буй, нечкә бил кебек традицион эпитетлар, авыздан энҗеләр чәчү, алтын алма кебек метафоралар лирик геройның эчке кичерешен, хис-тойгысын чагылдыру, шигырьнең поэтик яңгырашын, укучы күңеленә эстетик тәэсир итү дәрәҗәсен көчәйтү өчен хезмәт итә. *Җаным син, алтын алмам ла, Исемнән бер дә салмам ла!* [2: 400] *Билең нечкә, нәзек торыр, Буең зифа төзек торыр* [1:40]. «Җаным», «җанкаем», «чибәрем», «матурым», «алтыным» кебек сүзләр дә халыкның күңел рухын, матур эчке тойгыларын, хисләрен, сурәтләү объектына мөнәсәбәтне белдерәләр. *Сәхипҗамал чибәрем лә, И матурым, сөярем лә*! [2: 388], *И алтыным, табалмадым, Шәһәрдә һич тә, илләрдә* [2:390]. Чагыштыру объекты сыйфатында сайланган былбыл. *Үзең былбыл, күзең охшаш йолдызга* [1: 145], хур кызы *(Зифа буең,төсең,битең, Ки хур кызыйча мимылдай)* [2: 397] кебек халык җырларыннан алынган чараны да шагыйрь әнә шул максаттан файдаланган. Шулай ук шагыйрь әсәрләрендә чагыштыруларда киң куллана. *Тулган айга охшар сәнең йөзләрең бар, Бал-шикәрлән татлы сәнең сүзләрең бар, Зөһрә йолдыз кебек сәнең күзләрең бар, Кыяфәтең фәрештәгә биңзәр имди*.. [1: 43].

Кавыша алмаудан көчле сагыш тойгылары кичерүне Сак белән Сок язмышына охшату халык телендә, җырларда күп очрый. Моңа үзенең шигырьләрендә Кандалый да мөрәҗәгать итә: *«Ки, охшап Сак билә Сокка болай тормакымыз уңмай»…*.[1: 94].

Мәкаль-әйтемнәргә нигезләнеп, бөтен бер строфа төзү һәм аларны үзгәртү традициясе яшәп килә. Бу алымга Г.Кандалый да оста мөрәҗәгать иткән. Мәсәлән, «үткән эш кире кайтмас» дигән мәкальне ул үзенчә үзгәртә, аны метафорик сөйләм белән «ныгыта»: «*Еласаң да*

*кире дүнмәс, бу хәсрәтең уты сүнмәс, Сәнең чән кеше үкенмәс, ни күрсәң дә, абыстай ла»* [2: 403].

Г.Кандалыйның лексикасы бай, халыкчан. Тарихта беренче буларак, ул поэтик стиль рухына рус сүзләрен җайлаштыра. Аларны халык телендәгечә кулланырга тырыша: мажик (мужик), анфалит (инвалид), пушты (почта). *Бер анфалит кебек кайтып* [2: 411]*, Я бер надан сасы мажик* [1: 100]*, Ничә кәррә язам пуштым* [1: 111].

Борынгы төрки теленнән килеп, гади сөйләм лексикасына әйләнеп киткән кайбер сүзләр дә аның поэтик стилендә матур яңгыраш тапты. Халыкта «чук-чук сәлам» дип хат язу озак еллар дәвам итте. Г.Кандалый шигырьләрендәге «чук» сүзеннән дә әнә шул халык теле рухы сизелеп тора. *Йибәрсәң хатларый да чук, кавышмай җанымыз тынмай* [1: 94]. Югарыда телгә алынган гарык булу, теңкә кору кебек тәкъбирләр дә гади сөйләм өчен характерлы. *Гарык булып тәнең тиргә, Ботың буе агар йиргә* [1: 89].

Диалектизм булып санала торган тел берәмлекләрен дә мул кулланган: ерлай (җырлый), йил (җил), йәй (җәй), йир (җир) *Туңып йиргә егылырсың* [1: 91]. *Сәба йиле килде миңа бер заман* [1: 127].

Г.Кандалыйны Тукайга таба юл салган күренекле шагыйрь диләр. Шигырьләренең яшәү көче – аларның халыкчанлыгында.

**Әдәбият**

1. Кандалый Г. Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 187 б.

2. Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 558 б.

3. Кандалый Г. Сахибҗамал (Шигырьләр һәм поэмалар). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 127 бит.

4. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда: 2 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 566 бит.

# ЛОЖНЫЕ МЕЖЪЯЗЫКОВЫЕ СХОДСТВА КАЗАХСКОГО И ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

*Окасова М., КФУ, магистрант I курса*
*Науч. рук. – док. филол. наук, проф. Юсупова А.Ш.*

В родственных языках часто встречаются лексемы которые созвучны в обоих языках, но могут отличаться по значению. Такое явление может быть проблемой при изучении иностранного языка, при составлении словарей или же при переводе от одного языка в другой. Наличие таких проблем в сравнении двух или более языков неизбежна. Вопрос межъязыковой омонимии относится к области сопоставительной лингвистики. Наряду с проблемой исследования межъязыковых омонимов, само определение и понятие омонимии в лингвистике еще является спорным. Так как общепринятого понимания и термина к такому явлению в языкознании пока еще не существует. Но, в зарубежных научных трудах встречаются такие термины как: «ложные друзья переводчика», «межъязыковые омонимы», «межъязыковые проксиматы», «ложные межъязыковые сходства», «слова-аналоги», «лексические западни». Хоть и термин «межъязыковая омонимия» широко распространена, некоторые ученые не разделяют это понятие. Например, об этой проблеме пишет Е.А. Правда: «Омонимия, при любой интерпритации этого понятия, исходя уже из семантики самого термина, подразумевает прежде всего совпадение, тождество языковых форм в их устной или письменной реализации... Понимая термин буквально, вряд ли можно говорить о тождестве языковых форм в разных языках, имеющих различные фонологические системы, а тем более разные алфавиты... Кроме того, игнорируются межъязыковые различия, которые, хотя и могут оказываться нерелевантными для достижения конкретных целей коммуникации и не препятствовать в отдельных случаях её успешности, однако в принципе при обучении иностранному языку должны всегда быть в центре внимания»[2: 128]. Е.А. Правда выдвигает свой термин для межъязыковой омонимии: проксиматы. Ученая проксиматам дает такое описание: «проксимат – это факт иностранного языка (слово, словосочетание, морфема или др.), который имеет внешнее сходство с каким-либо фактом родного языка, но отличается от него семантическими, грамматическими, стилистическими или другими свойствами и поэтому способен вызвать ошибку при его использовании в речи на данном иностранном языке»[3: 171]. Термин проксимат происходит от латинского слова proximus – «весьма близкий; наиболее сходный».

Омонимия может возникать по разным причинам: из-за отличии в алфавитной системе, из-за заимствовании иноязычных слов, при котором адаптируя его в свой язык, слово может видоизменятся, из-за различия в фонологической системе и м.д. Различные примеры семантической деривации имеются во многих тюркских языках. Также омонимия может присутствовать в языках которые используют разную или же одинаковую алфавитную систему, даже если эти языки не являются родственными. К примеру, если сравнить казахский язык с корейским языком в котором используется совсем другая алфавитная система, встречаются слова схожие по звучанию, но имеющие разные значения. Например: кор. 값 (кап) – имя сущ. «цена, ценник», на каз. *қап* – 1) имя сущ. «мешок», 2) имя сущ. «футляр, чехол», 3) межд. «как жаль» (возглас сожаления), кор. 가방 (кабаң) – имя сущ. «сумка», каз. *қабан* – имя сущ. «кабан». Татарский и казахский языки относятся к тюркским языкам, имеют схожий алфавит на основе кириллицы, но, все же встречаются много примеров обманчивых межъязыковых сходств. Например, лексема *аяз* на татарском означает «ясный, безоблачный день», а на казахском имеет противоположное значение *аяз* – «мороз». Такой вид проксимата Е.А. Правда относит к окказионатам[3: 172], содержащим в своем значении противоположные семы. Окказионаты – тип семантических проксиматов, обозначающие далекие друг от друга понятия, то есть сходство между словами случайны. Например, на татарском лексема *аң* означает «сознание, разум», а на казахском *аң* – «животное». Другие примеры: тат. *аксерке* – «уксус», каз. *ақсерке* – «рыба белуга», тат. *алан* – «лесная поляна», каз. *алан* – «детёныш барса», тат. *арыту* – «утомлять», каз. *арыту* – «худеть» (дословно заставить похудеть), тат. *түгел* – частица «не», каз. *түгел* – «весь, целиком», тат. *асаба* – «вотчинный наследник», каз. *асаба* – «тамада».

В перекрестных связях этих языков не может быть единиц, полностью совпадающих по звучанию или же написанию. Они могут отдаленно напоминать знакомое слово при произношении на родном языке.. Некоторые примеры: тат. *аҗгыру* – «злиться, разъяриться», каз. *азғыру* – «искушать», тат. *аймылыш* – «разъехаться», каз. *аймалас* – «ласкаться», тат. *кабалан* – «суетливый», каз. *қапалан* – «расстроиться», тат. *ашыгу* – «торопится», каз. *ашығу* – «голодать», тат. *алпавыт* – «помещик», каз. *алпауыт* – «большой», тат. *бутау* – «путать, запутать», каз. *бұтау* – «рубить, нарубить». К межъязыковым проксиматам можно отнести и диалекты на казахском и татарском языках. К примеру, слово *бадран, гөлбадран* на татарском является названием лекарственного растения «пижма», а на казахском языке *бадран* [1: 394] (также

встречается вариант *бәдрен*) является диалектом имеющий значение «огурец», используемый в Жамбульской области и Южной части Казахстана. При возникновении межъязыковых ассоциаций некоторые слова иностранного языка представителям иного народа могут казаться смешными, порой нелепыми. Например, слово «мясо» на татарском – *ит*, а на казахском – *ет*. Если татарин скажет казаху: *мин ит ашадым* – «я поел мясо», казах будет в недоумении, так как слово *ит* на казахском переводится как «собака», и если перевести дословно эту фразу будет «я поел мясо собаки». В большинстве случаев возникновения таких комичных проксиматов связано с тем, что нейтральное слово другого языка ассоциируется с более экспрессивным, табуированным, постыдным словам родного языка.

Исследования межъязыковых проксиматов в близкородственных языках является интересной и актуальной темой для лингвистики. Так как, вопросы, почему же в развитии исторически родственных языков произошла семантическая дивергенция, и почему же одинаково звучащие слова имеют разные значения в родственных языках, требуют ответа. Близкое родство казахского и татарского языка проявляется наиболее ярко в их словарном запасе. Лексикон у тюркских языков очень богатый и обширный, материала для исследования межъязыковых сходств тоже будет предостаточно. А изучение и выявления таких несоответсвии очень важны, потому что при изучении иностранного языка или при использовании переводчика, мы склонны переносить наши родные языковые привычки в другую языковую систему, потому что чаще всего влияние родного языка и культуры превосходят и вставят в невыгодное, порой даже в неловкое положение толкая на ложные аналоги знакомых нам укоренившихся слов. И по этим выше перечисленным примерам можно удостоверится что, несмотря на генетическое родство языков и географическую близость стран и некое сходство в менталитетах и культурах, имеется большое количество таких отличии.

**Литература**

1. Аманжолов С. Қазақ тілі диалектологиясы мен тарихының мәселелері. Оқу құралы. – Алматы: Сөздік-Словарь, 2004. – 536 с.

2. Правда Е.А. Межъязыковые проксиматы в параллелях сербского и русского, словацкого и русского языков: типы проксиматов // Вестник ВГУ. Вып. 1. – Воронеж: ВВГУ, 2010. – С. 128-129.

3. Правда Е.А. Межъязыковые проксиматы в параллелях сербского и русского, словацкого и русского языков: отношения между проксиматами // Вестник ВГУ. Вып. 2. – Воронеж: ВВГУ, 2010. – С. 171-175.

# MİLLİ-MƏDƏNİ XÜSUSİYYƏTLƏRİN DİLİN LEKSİK SİSTEMİNDƏ İFADƏ OLUNMASINA DAİR

*Putayeva E., Filologiya üzrə fəlsəfə doktoru, Azərbaycan Dillər Universiteti*

Müasir dövrdə ingilis dilinin qlobal xarakter daşıması millətlərarası ünsiyyətin reallaşması üçün dil bilgilərinin labüdlüyü məsələsini ortaya çıxarır. Hər hansı bir dilin öyrənilməsi həmin dildə danışan xalqın mental və xarakterik xüsusiyyətlərinin də öyrənilməsinə rəvac verir. XX əsrin sonlarına doğru bu istiqamətdə yeni araşdırmaların və təhlillərin aparılması "linqvokulturologiya" kimi yeni bir sahənin yaranmasına gətirib çıxardı. V.A.Maslovanın fikrinə əsasən, linqvokulturologiya linqvistikanın yeni bir qolu hesab olunur və bu sahə dilçiliklə mədəniyyətin toqquşması fonunda meydana çıxmışdır [1: 9]. Başqa sözlə desək, dilçilik, mədəniyyətşünaslıq, etnoliqvistika və mədəni antropologiyanın nəticələrini özündə ehtiva edən yeni bir elm sahəsi linqvokulturologiya adlanır [1: 32].

Bir çox tədqiqatlar sübut etmişdir ki, hər hansı bir ölkənin mədəniyyəti ilə tanış olmaq, mədəniyyətlərarası ünsiyyətin baş tutbbbbbması dilin mənimsənilməsi prosesini daha da asanlaşdırır. Xalqların leksik fondda öz əksini tapan mədəni və milli-mənəvi dəyərlərinin təhlili mədəniyyətlərarası ünsiyyətin də daha müvəffəq həyata keçirilməsinə yol aça bilər. Xüsusi olaraq qeyd edə bilərik ki, mədəniyyət, məişət, tarix və dilin lüğət fondu bir çox hallarda milli mentaliteti özündə ehtiva edir. Xalqın təbii yaşam şəraiti, adət və ənənələri, ictimai fikir tarixi, elmi inkişafı, mədəniyyət və incəsənəti özünü istənilən formada mentalitetdə əks etdirə bilər [3: 304-306].

Son onilliklərdə linqvokulturologiya sahəsində bir sıra anlayışlar meydana çıxmışdır ki, onların sırasında linqvokulturoloji yanaşma, dünyanın dil mənzərəsi, mədəni boşluqlar, milli-mədəni komponent, fon bilikləri, nitq vərdişləri və davranışları, ünsiyyət mədəniyyəti kimi ifadələrə daha çox rast gəlinir.

Mədəniyyətlərarası ünsiyyətdən söz açıldığı zaman yuxarıda adı çəkilən komponentlərin effektivliyi və bütövlükdə ünsiyyət prosesi milli-mədəni xüsusiyyətlərdən birbaşa asılı olur. Milli-mədəni spesifiklik dedikdə, milli birliyin mədəni ənənələri, milli davranış normalarının özünəməxsusluğu, millətin sosial simvolizmi nəzərdə tutulur. Bu komponentlər arasında dil sistemi üçün spesifik olan nümunələr – frazeologizmlər, metaforlar, müqayisəli ifadələr və s. xüsusi yer tutur ki, bu ifadələr dilin leksik sistemində yeni söz qruplarının yaranmasına gətirib çıarır. Digər tərəfdən, milli-mədəni xüsusiyyətlər yalnız dil səviyyəsində deyil, həm də kommunikasiya iştirakçılarının nitq davranışlarında özünü büruzə verir.

Son dövrlərdə dilçilik ədəbiyyatında “dil mentallığı” termini istifadə olunur ki, bu halda müəyyən dövr insanı üçün xas olan, tarixi və sosial proseslərə təsir edə bilən və dil strukturları ilə müəyyənləşən mentalitet toplusu nəzərdə tutulur [2].

Mentalitet ümumi dünya görüşünün struktur tərkibi hissəsidir, mentallıq isə öz növbəsində mentalitetin funksionallaşması və realizasiyası hesab olunur. Dil və mədəniyyət arasındakı sıx əlaqə təkzibolunmazdır. Belə ki, dil mədəniyyəti, ətraf aləmi, ictimai dərketməni, adət-ənənə və dəyərlər sistemini ifadə edən real güzgüdür. Dilin leksik sistemi, ata sözləri və məsəllər, bədii və elmi ədəbiyyat, folklor, yazılı və şifahi nitq formaları xalqın mədəni dəyərlərində qorunub saxlanılır. Bu yolla dil və mədəniyyətin bir-birindən ayrılıqda mövcud olmaması fikrinə gəlib çıxırıq, çünki mədəniyyət bizim həyat tərzimizi əks etdirən praktik bacarıq və vərdişlərin birləşdiyi sosial mirasdır [2].

Bu şəraitdə dil mədəniyyətin ayrılmaz tərkib hissəsi kimi insan fəaliyyətinin müxtəlif sahələrində əldə olunan nəticələrin külliyyat halında ifadə tərzidir. Dil həm də öz-özlüyündə güclü ictimai “silah” rolunu oynayaraq, mədəni dəyərlərin və adət-ənənələrin qorunması və ötürülməsinə xidmət edərək formalaşır.

Bu sahədə təhlil olunmalı digər bir məsələ dil və etnosun qarşılıqlı münasibətinin tədqiqi məsələsidir. Bir çox müxtəlifdilli etnosların olması müddəasını göz önündə tutaraq yalnız bir dildə danışan etnosların olmasını da təkzib edə bilmərik. Məsələn: Osmanlı ordusunda sultanın ordu komandanı türk dilində əmr verir, anası ilə polyak dilində danışır, bazarda yunan dilində ünsiyyət qurur, fars dilində şeir oxuyur, ərəb dilində dua edirdi [4: 47]. Bu şəkildə etnosla dil arasında sadə korrelyasiya əlaqəsinin təhlilini apardıqda linqvokulturologiya bu münasibətin daha mürəkkəb olması fikrini iddia edir.

Yuxarıda qeyd edilənlər bizə bu sahədə müəyyən nəticələr əldə etməyə əsas verir. Belə ki, kommunikasiyanın millətlərarası və mədəniyyətlərarası kontekstdə həyata keçirilməsi fikrini əsas götürərək iddia edə bilərik ki, məhz müxtəlif mədəniyyətlərin nümayəndələri mədəniyyəti kommunikativləşdirirlər. Müəyyən cəmiyyətdə göz açan insan orada mövcud olan norma və qaydaları mənimsəyir və bu toplunu ünsiyyətin əsas üsulu kimi formalaşdırır. Mədəniyyətin və kommunikasiyanın mahiyyətini aydınlaşdırmaq üçün qeyd edə bilərik ki, mədəniyyət şüurun proqram təminatı hesab oluna bilər və bu da özünü milli mentalitet bazasında xüsusi şəkildə dilin leksik sistemində ifadə etmiş olur.

**Ədəbiyyat**

1. Маслова В.А. Лингвокультурология. Учеб. пос. – М.: Издательский центр “Академия”, – 2001. – 208 с.

2. Новикова О. Н. Национальный характер, менталитет и язык общения как национально-культурные аспекты коммуникативного поведения, № 3, 2015. URL: https://science.rfei.ru/ru/2015/3/129.html.
3. Горбань А.О. Отражение менталитета в лексике английского языка // «Молодой учёный». – 2021. – № 45 (387). – С.304-306.
4. Гумилев Л.Н. Этногенез и биосфера Земли. – М.: Айрис пресс, 2001. – 247 с.

.

# ТАВЫШ ҺӘМ МӘГЪНӘ АРАСЫНДАГЫ БӘЙЛӘНЕШ (Г. ШАҺБАН ШИГЫРЕ МИСАЛЫНДА)

*Рәхмәтуллина А., КФУ, I курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Һадиева Г.К.*

Чит илләр психолингвистикасында фонетик мәгънә һәм фонетик ассоциацияләрнең барлыгы эксперименталь рәвештә расланган. Телләр үсешендә фонетик мәгънәнең мөһимлеге билгеләнде. Тавышларның экспрессив һәм символик мәгънәләре барлыгы да танылды. Фәнгә «фонетик мәгънә», шулай ук «фонетик мәгънәнең төс аспекты» терминнары кертелә, фоносемантик кыр феномены сурәтләнә [3: 28].

Төрки телләрнең фонетикасын тикшерү исә профессор В. Богородицкийның татар теленнән хезмәтләре белән тыгыз бәйләнгән. Фәндә новатор һәм Россиядә эксперименталь фонетика кабинетына нигез салучы буларак танылу алудан кала В.А. Богородицкийның мөһим казанышы булып беренче тапкыр татар телен өйрәнгәндә инстументаль тикшеренүләр куллануы, шулай ук җирле халыктан эксперименталист кадрлар әзерләргә омтылуы тора. В.А. Богородицкий, эксперименталь график җайланмалар ярдәмендә, коралсыз күзәтү өчен мөмкин булмаган мәгълүмат формалаштыра. Бу, мәсәлән, сүз элементларының секунд дәвамындагы озынлыгы; аерым тавышлы элементларга бәйле тон, амплитуда хәрәкәте һ.б. [2: 11] Эксперименталь-фонетик тикшеренүләргә нигезләнеп, татар һәм рус телләренең авазлары чагыштырып бирелә; сүздәге урынына бәйле рәвештә авазларың озынлыгы, тавыш югарылыгы үзгәрү кебек нәтиҗәләр ясала, сингармонизмның төп үзенчәлекләре күрсәтелә.

Югарыда әйтелгәннәргә бәйле төстә тавыш белән әсәргә салынган мәгънә арасындагы бәйләнеш кызыксыну уята, чөнки әлеге проблема актуаль кала бирә, аеруча да балалар сөйләме арасында. Мисал өчен без Гөлүсә Шаһбанның “Әнкәй, җаным” шигырен тикшерергә булдык. Шигырьне укучы мәгънә ягына гынамы, әллә мәгънәне белдерү планына да игътибар итәме дигән сорауга җавап эзләдек.

Анализ ясау барышында махсус графикалар ярдәмгә килде. Алар компьютер программасы аша гамәлгә ашырыла. Без Speech Analyzer платформасы белән эш иттек. Тикшерү предметы булып сөйләмнең яңгыраш ягы тору сәбәпле, берничә параметр аерып каралды. Бу – интонация, ешлык һәм интенсивлык.

Г. Шаһбан иҗат иткән «Әнкәй, җаным» шигъри әсәрен «Тәртип» радиосында «Тәртипле иртә» интерактив тапшыруын алып баручы Айгөл Нәбиуллина яңгырата. Әсәрне уку барышында ясалган

тукталышларның озынрак булуы бәхәссез. Строфа саен гадәттә 2 - 2,3 с. пауза ясалса, ике юлны укыганнан соң 1,3 с. тирәсе туктап торыла. Бу рәвешле ашыкмый сөйләү белән шигырьне укучы тыңлаучыларны үзенә җәлеп итә, билгеле бер мәгънәне тапшырырга омтыла һәм, әлбәттә, әсәрне үтемле итә. Диктор соңгы строфага аеруча игътибарны күп юнәлтә. «Еллар» сүзеннән соң, «чәчләреңә» дигәч 1 с., «ак» диюгә 0,8 с. , «сибелә» алдыннан 1,1 с. пауза эшләнелә.

Шигырьдәге тукталышларның юкка гына ясалмавы аңлашыла ки, чөнки паузалар аша әни кешенең чәчләренә еллар чал кертүен, әнинең еллар узган саен гына кадере артуын күрәбез.

Интенсивлыкка күчсәк, ул 39,2 дб белән «юлга» сүзендә күзәтелә. «Язмыш җиле» һәм «үпмәгән» дигәндә күрсәткеч 43,4 дб югарылыгына менә. 46,6 дб «йөзләреңнән» һәм иң югары күрсәткеч буларак «шулай да» каршылыгында 62,4 дб белән билгеләнә. Әсәрне уку барышында төп йөкләнеш көчле позициягә чыгарылган исемгә, ягъни «әни»гә төшәргә тиеш иде, ләкин сөйләүче тарафыннан башка сүзләргә һәм сүзтезмәләргә игътибар бирелә. Шуңа да карамастан, сөйләүче ясаган паузалар ананың язмыш язган каршылыкларга баш имичә, йөзенең саф һәм горур халәттә каршы тора алуын, киресенчә, авырлыкларны шатлык белән күмеп яши белүен бәян итә.

Тон ешлыгының иң түбән күрсәткече 40,70 Гц, ә иң югарысы – 408 Гц. Беренчесе «кызартмаслар» сүзендә, икенчесе «Изгелеккә таба юллар салдың» юлында ирешелә. Моннан чыгып, ананың төп функцияләре алга сөрелә. Алар дөрес тәрбия бирү һәм юл күрсәтүдән гыйбарәт.

Гөлүсә Шаһбанның «Әнкәй, җаным» шигырендә 273 сузык аваз бар. Алгы рәтнекеләр 153 булса, арткы рәт сузыклары 120гә тигез. Моңа бәйле әсәрнең күтәренке рухта иҗат ителүен билгели алабыз. Шигырьдә алгы рәт сузыклары өстенлек иткәнгә күрә әсәр эмоциональ башкарылырга тиеш иде, әмма Айгөл Нәбиуллина аны салмак һәм тынык интонациягә сала. Мәгънәне тулы дәрәҗәдә ачып бетерүгә дә бу комачау итә. Иң элек шигъри әсәрнең мәгънәсенә төшенү рас. Шуннан чыгып кына паузаларны билгеләү дөрес булыр.

Гомумән алганда галимнәрнең борынгы заманнардан ук тавыш һәм мәгънә арасындагы бәйләнеш соравы белән кызыксынуын әйтә алабыз. Хәзерге психолингвистика өлкәсендә әлеге проблема хакындагы тикшеренүләр зур масштабка ия. Сорау тулысынча ачыкланып бетмәсә дә, түбәндәге фактны расларга мөмкин: сөйләм авазларының мәгънәсе бар, әмма һәр галимнең бу проблеманы үзгә аңлатуы яши. Бу өлкәдә дәвам итүче тикшеренүләр фоносемантиканың

фән буларак алга таба үсешенә дә, бүгенге көндә балалар сөйләменнән үк килгән әйтелеш проблемасын да хәл итергә ярдәм итәчәк.

**Әдәбият**

1. Байчура Ү.Ш. Татар теленең кайбер фонетик үзенчәлекләре (Экспериментал фонетик мәгълүматлар буенча) // Татар теле һәм әдәбияты мәсьәләләре. – Казан, 1963. – 127-140 б.

2. Богородицкий В.А. Заметки по экспериментальной фонетике. Вып. I. – Казань: Типография Императорского Университета, 1896. – 31 с.

3. Фадеева Е.Н. Фоносемантическая характеристика индивидуального стиля автора: дис. … канд. филол. наук [Электронный ресурс]: электронная версия диссертации. – Тула, 2004.

4. Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 108 б.

5. Марухина С.А. Методы фоносемантического исследования поэтического текста // Ярославский педагогический вестник. – 2013. – №4. – 184-187 с.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ «ОЯТ» ЛЕКСЕМАСЫ

*Рәшитов Э., Казан ш., 121 нче лицей, X сыйныф*
*Фән. җит. – югары кат. туган тел һәм әдәбияты укытучысы*
*Миннуллина А.И.*

Сүз һәм төшенчә янында йөри торган тагын бер термин – лексема. Лексема (грек. lexis – сүз) – сүзлек составының конкрет мәгънәгә һәм грамматик формаларга ия булган төп мәгънәви берәмлеге.

Хезмәтебездә без оят лексемасын тикшерергә алындык һәм татар телендә оят лексемасының лексик-семантик һәм ассоциатив кырларын ачыклауны максат итеп куйдык. Хәзерге әдәби татар телендә оятның дериватлары (ясалма сүзләр):*оялмыйча*, *оятсызларча* (оятсыз рәвештә), *оялту* (үкенү, оялу хисе тудыру; шаяртып, көлеп, уңайсыз хәлдә калдыру), *оялу* (нәрсә дә булса эшләргә тартыну, уңайсызлану; кем дә булса алдында оятлы булу), *оялчан* (үтә тыйнак, тартынучан; юкка-барга оялучан; оялу билгеләрен чагылдырган), *оялчанлану*(оялчанлык күрсәтү), *оялчанлык* (оялчан булу сыйфаты), *оялыш* (оялу билгесе), *оятлы* (намусы булган, ояла белә торган; гаепле хәлдә, уңайсыз; түбән, хурлыклы), *оятлык* (оят өлеше), *оятсызлык* (үтә әдәпсезлек, тыйнаксызлык) [3: 158].

“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә оят сүзенең түбәндәге мәгънәләре бирелгән: 1. Нинди дә булса бер начарлык яисә гаеп эш эшләүне аңлаудан туган көчле уңайсызлану, үкенү, хурлану хисе. *Оятын кая куярга белмәү.*Димәк, оят – кешенең үз хәрәкәтеннән, дәлилләреннән, әхлакый сыйфатларыннан хурлануын чагылдыра торган әхлакый хис дип әйтә алабыз.

Оятның синонимнары – гарьлек; хурлык; гарь; мәсхәрә; йөз карасы; рисвайлык. Сүзнең килеп чыгышын Р.Әхмәтьянов *увут, угам, угиам* формалары белән бәйли.

Оят лексемасы кергән мәкаль һәм әйтемнәргә күз салсак, әлеге лексеманың аларда киң кулланылышка һәм күп мәгънәләргә ия булуын әйтеп була. Кайбер мәкаль һәм әйтемнәрдә оятны башка төшенчәләр дә алмаштыра: мәсәлән, *намус, кыюлык, вөҗдан, әдәп* һ.б.

Мәкаль һәм әйтемнәр, гадәттә, үзенчәлекле фольклор жанры буларак өйрәнелә. Әмма аларны хәзерге лингвистикада өйрәнүнең перспективалары бик зур дип әйтеп була, чөнки лингвокультурологиядә билгеле бер халыкның мәдәнияте, тарихы, көнкүреше, әхлак кагыйдәләре белән бәйләнгән мәкаль һәм әйтемнәргә игътибар юнәлтелә.

Оят лексемасы кергән мәкаль һәм әйтемнәргә мөрәҗәгать итсәк, ул аларда түбәндәге мәгънәләрдә очрый:

Байлык морат түгел, ярлылык оят түгел.

Адәмнең ояты битендә

Кешедән оялмаган кешенең йөзе олтан.

Оят юкта иман юк.

Ләкин шуны да билгеләргә кирәк – кайбер очракта мәкальләрдә оят сүзе аталмый, ягъни кулланылмый. Шулай да, анда сүзнең нәрсә турында барганын абайлап алып була. Мондый мәкальләрдә нигездә я берәр оятлы эш, кешенең тәкәбберлеге,кыюлыгы, нәфесе, гадәтсезлеге, комсызлгы белән дә бәйле була, я оялу (уңайсызлану, кыенсыну, тартыну мәгънәсендә) күрсәтелә.

Акчаң булмаса да, вөжданың булсын.

Вөжданы пакь –йөзе ак.

Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен.

Оят лексемасы матур әдәбиятта да бик еш очрый. язучы һәм шагыйрьләр оятны кеше өчен иң кирәкле әхлакый сыйфатларның берсе итеп кабул иткәннәр,кеше өчен иң кирәкле, кешегә дәрәҗә алып килә торган сыйфат дигән фикердә торалар. Шулай итеп, әдәбиятта да оятны тәрбияле кешегә генә хас бер сыйфат итеп күрсәтүче язучылар һәм шагыйрьләр бик еш очрый.

Мәхәббәт җырларында оят сүзе аеруча еш очрый, хәтта кабатланып килү очраклары да күзәтелә:

Исемен әйтте: “Шәмсинур, – ди. –

Ярый. Егет, хуш, сау бул!” – ди,

*Оялып* кына, *оялып* кына. (“Шәмсинур”)

Борынгы ядкарьләрнең берсе булган, Казан ханлыгы чорында яшәгән һәм иҗат иткән әдип шагыйрь Мөхәммәдьярның “Нуры содур” (“Күңелләр нуры”) дип исемләнгән дидактик поэмасының бөтен бер бүлеген оят булуга багышланган. Поэмадагы фикерләр аеруча гыйбрәтле һәм уйландырырлык.

Кем эчендә саклый алса оятын,

Бу хәдиснең чыгарыр ул атын.

Бу хәдиснең мәгънәсен яхшы ишет:

Оят иманнан килә ул, и егет.

Димәк, оят күп мәгънәгә ия булган сүз булганга күрә, кешеләр дә аны төрлечә аңлый. Кайберәүләр оятны хурлык,тәрбиясезлек дип кабул итсә, икенчеләр аны оялу, тартыну мәгънәсендә куллана.

Соңгырак чорга караган Г.Тукай әсәрләрендә “оят” лексемасы аеруча күп очрый.Билгеле булганча, Г.Тукай мәгърифәтче шагыйрь, аның күп кенә әсәрләре дидактик принципка нигезләнгән. Әйтеп узганча, оят – кешенең әхлакый, эстетик сыйфаты, һәм аның дидактик рухтагы әсәрләрдә очравы бик табигый хәл.

Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә,

Аһ, оят , хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: борынгыдан килгән күркәм сыйфат – оялу ул әле курку дигән сүз түгел, шуңа күрә комсызлык, тәкәббәрлек кебек сыйфатлар мактауга ия түгел, тыела белү дә кешегә хас булырга тиеш. Ә инде әшәкелек, начарлык, зыян кылу моны эшләүче хуҗасына бары тик оят, яман сүз генә китерә, һәм бу очракта инде уңайсызлану хисе генә түгел, ә, бәлки, ояты белән бергә түбәнсезлеген дә тоя.

**Әдәбият**


1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы: Педагогия институтлары һәм колледжлары өчен кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 93 б.
2. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 371 б.
3. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясенең нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 220 б.

# ЛЕКСИКА МОЛОЧНОЙ ПИЩИ В ЯКУТСКОМ ЯЗЫКЕ

*Романова А., КФУ, магистрант II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Нурмухаметова Р.С.*

Изучение народных терминов питания вызывает интерес из-за их значимости для отражения материальной и духовной культуры народа. Эта лексика еще мало изучена в тюркских языках и имеет историческую ценность, поэтому требует комплексного анализа с точки зрения различных отраслей языкознания. Язык играет важную роль в формировании менталитета этноса, народа или нации, поэтому изучение народных терминов питания имеет большое значение для понимания культурного контекста.

Исследование национальной кухни сейчас вызывает большой интерес из-за возросшего в последнее время интереса к традиционной культуре, возрождению традиций и стремлению разнообразить рацион питания. В этом контексте исследование народных терминов питания может внести свой вклад в сохранение, возрождение и популяризацию культурного наследия. Пища является одним из компонентов материальной культуры каждого народа, и изучение ее терминологии имеет большое значение для понимания культурного контекста. Например, на протяжении своей долгой истории якуты разработали собственную систему сбалансированного питания с рациональным соотношением всех его элементов, необходимых для здорового обмена веществ.

Молочная и кисломолочная продукция играют важную роль в якутской национальной кухне, поскольку предки якутов занимались скотоводством. Сами названия этих продуктов на якутском языке – «Үрүҥ ас» (белая еда), «Үрүҥ илгэ» (белое изобилие) – свидетельствуют о значительном месте молочной пищи в жизни этого народа. В древности якуты считали, что они произошли от Үрүҥ Аар Тойона – Светлого Божества Юрюнг Ар Тойон, – и рассматривали молочную пищу как дар своего Божества для поддержания своей жизни. Таким образом, прилагательное «Үрүҥ» в якутском названии молочных продуктов указывает на «светлый, святой» или «связанный с Божествами» и отражает древние корни почитания этого народа к молочной пище [5: 234].

Семантическая классификация якутских наименований молочных продуктов включает в себя следующие лексико-тематические группы: 1) «Общие слова»; 2) «Жидкие молочные продукты»; 3) «Кисломолочные продукты»; 4) «Масло коровье и масляные продукты».

**Общие слова.** як. **сөлөгөй** «1. *фольк.* Киһиэхэ күүс-күдэх биэрэр улахан иҥэмтиэлээх аһылык, сүмэ. ○ Жидкая пища или напиток, обладающие живительной силой, восстанавливающие жизненную энергию. 1. *высок.* Үүт ас, үрүҥ ас. ○ Молочная пища» [1: 66].

як. **тунах** «*устар. диал.* (верх.) Сайын эрдэ, үрүҥ ас дэлэйиитэ; ол кэмҥэ үрүҥ аһы тэниччи тардан тэриллэр ыһыах. ○ Молочная пища, обилие молочных продуктов в пору отела; якутский летний праздник с обилием молочной пищи, кумыса» [2: 247].

**Жидкие молочные продукты.** як. **тоҥ үүт** «Иһиккэ кутан тоҥоруллубут үүт. ○ Молоко, замороженное в посуде» [1: 451].

як. **үүт I** «Үүтүнэн иитээччилэр уонна дьахтар саҥа төрөөбүт оҕолорун эмтэрэллэригэр эмиийдэригэр үөскүүр маҥан өҥнөөх убаҕас. ○ Белая жидкость, выделяемая грудными железами женщин и самок млекопитающих для вскармливания младенца, детеныша, молоко» [1: 588] // як. **эмий** «*диал.* (долг.) Үүт. ○ Молоко» [2: 320].

**Кисломолочные продукты.** як. **бөлөнөх** «Үүт сиикэйдии аһыйан бөлөнүйбүтэ. ○ Густое закисшее некипяченое молоко, простокваша» [1: 446].

як. **быырпах** «Ынах үүтүн аһытан көөнньөрөн оҥорбут утах, ынах үүтүн кымыһа. ○ Кумыс из коровьего молока» [1: 811].

**Масло коровье и масляные продукты.** як. **арыы II** «Сүөгэйи ытыйан уонна иирдэн оҥорор үрүҥ ас. ○ Сливочное масло» [1: 578] // як. **һыа** «*диал.* (долг.) Арыы. ○ Масло» [2: 229].

як. **дьэҥкир арыы** «Ынах уулллубут арыыта. ○ Топленое коровье масло» [1: 579] // як. **буһуу арыы** «*диал.* (бод., вил., олекм., сад. под. (мирн.), сунт., зар. под. (вил.)) Буспут арыы. ○ Топленое масло» [2: 56]; як. **буһук арыы** «*диал.* (зар. под. (вил.))» [2: 55]; як. **оргуйбут арыы** «*диал.* (мом.)» [2: 145].

Почти во всех областях науки можно найти сложные слова, в том числе в лексике, связанной с молочными продуктами. Изучение лексических наименований молочных продуктов, составленных из сложных слов (т.е. образованных путем объединения слов), можно провести в двух аспектах – лексико-семантическом и структурно-грамматическом, так как они обладают специфическими словообразовательными свойствами. Важно отметить, что композиты в контексте лексико-семантического аспекта образования якутских слов практически не изучались.

Современное восхищение традиционной культурой и стремление к разнообразию рациона питания подчеркивают актуальность изучения национальных кулинарных традиций.

Исследование народных терминов питания способствует сохранению, возрождению и популяризации культурного наследия, обогащая общее представление о многообразии кулинарных традиций различных народов.

**Литература**

1. Большой толковый словарь якутского языка в 15 т. URL: https://e.nlrs.ru/ (дата обращения: 13.02.2019)

2. Диалектологический словарь якутского языка / сост. П.С. Афанасьев, М.С. Воронкин, М.П. Алексеев. – М.: Наука, 1976. – 392 с.

3. Диалектологический словарь якутского языка: Дополнительный том / сост. М.С. Воронкин, М.П. Алексеев, Ю.И. Васильев. – Новосибирск: ВО «Наука», 1995. – 296 с.

4. Саввин А.А. Пища якутов до развития земледелия (опыт историко-этнографической монографии) / подгот. текста, ввод. ст., послесл., коммент. и примеч. д. и. н. Е.Н. Романовой (отв. ред.); литер. ред. Н.И. Дегтярева. – Якутск: ИГИ АН РС (Я), 2005. – 376 с.

5. Серошевский В.Л. Якуты. Опыт этнографического исследования. 2-е изд. – М., 1993. – 736 с.

# КЕШЕ КЫЯФӘТЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЮРАМЫШЛАР

*Садыйкова А., Саба р-ны, Шәмәрдән лицее "Үсеш", X сыйныф*
*Җит. – Сабирова Р.А.*

Юрамышлар халыкның мифологик күзаллауларында мөһим урын тоткан жанр. Аны хәтта мифларның башлангычы, нигезе, тамыры, идеясе дип атарга мөмкин. Чөнки һәр юрамыш – бөтен бер мифологик сюжет тууга сәбәпче булган мотивны, сурәт-образны, эшгамәлне үз эченә ала.

Бик борынгы заманнардан ук кешеләр, үзара аралашканда, берберсенең кыяфәтенә,аеруча йөз-чыраена, башына, гәүдә төзелешенә карап,каршысында торган кешенең холык-фигылен, тәртибен, табигатен, сәламәтлеген, хәтта уй-ниятләрен белергә тырышканнар. Шул рәвешле кеше кыяфәте белән бәйле юрамыш-сынамышлар барлыкка килгән. Кыяфәт белән бәйле юрамышларның тууына сәбәпче булган күпчелек мифлар эзсез югалган, әмма «исән калган» нарын күпмедер дәрәҗәдә күзалларга мөмкин. Мәсәлән, борынгы ышанулар буенча, кешенең сул ягы – эти ягы, уң ягы әни ягы дип бәян ителә. Шул рәвешле, уң як бөер һәм уң як үпкә әнигә карый, ә сул як бөер белән сул як үпкә эти ягына буйсына. Кеше кыяфәте белән бәйле юрамышларның күбесе «Сул як, уң як»принцибына корылган. Мәсәлән, *«Кешенең иңбашы (кулбашы) уң якка иңеп, басылыбрак торса – яхшы кеше, гадел, ихлас"*. Халык мифологиясе буенча, уң як иңдәге фәрештә – изге фәрештә. Ә инде "*кешенең сул як иңбашы (кулбашы) басылыбрак торса, безнең алда – эчкерле кеше, яшертен,астыртын эш йөртүчән бәндә";* аның иңендә явыз рухлар, шайтани затлар утыра. Гомумән алганда, "уң" якны тасвирлаган юрамышлар – уңай сыйфатлар һәм яхшылык, уңыш белән, ә "сул" як тискәре сыйфатлар һәм явызлык, уңышсызлык белән бәйле. Мәсәлән, *"Күз кабагының уңы тартса – яхшылыкка, сулы тартса – начарлыкка", "Уң бит очы кычытса – сөенеч, сул бит очы кочытса – көенеч"* һ. б.

Кеше кыяфәте белән бәйле юрамышлар тематик яктан бик күп төрләргә бүленә: баш, муен, колак, күз, авыз, тел, чәч, сакал-мыек, иреннәр, буй-сын белән бәйле юрамышлар. Шулар арасында баш белән бәйле юрамышлар зур урын алып тора, чөнки элек-электән кешенең акыл-зиһен дәрәҗәсе аның башы, баш төзелеше белән бәйләнгән дип каралган. Мәсәлән, "*Башы артка чыгыбрак торган кеше артык акыллы, сабыр була", "Башы маңгай өлешендә алгарак чыкса, бу кеше гаять зирәк һәм сизгер булырга тиеш",* дип уйланылган. "*Башын югары күтәреп, башын артка кәкрәйтеп йөрсә – тәкәббер һәм мин-*

*минлеге көчле кеше"* дип юраганнар. Кешенең уй, зиһен, акыл көчен борын белән дә юраганнар: *"Зур борын – күп уйлаучан", "Ян-яктан борын тишекләре кабарып торса – ачык фикерли алмый, тотнаксыз".*

Кыяфәтнамә юрамышлар арасында күз, күзнең төсе һәм миңнәр бәйле юрамышлар аеруча киң таралган. Мәсәлән, *"Зур күзләр – бик дәртле һәм хәйләкәр кеше", "Кысык күзләр – көчле ихтыярлылык һәм түземлелек, шул ук вакытта үзсүзлелек билгесе", "Муены миңле – бәхетле", "Күзе миңле – яшьле", "Авызы миңле – ашлы, мул тормышлы".*

Тагын шунысы кызыклы: кеше тәнендәге һәр әгъза, аның кыяфәтендәге һәр чалым, төс, рәвеш организмның хәзерге рухи - психологик хәле, сәламәтлекнең бүгенге торышы хакында хәбәр итә. Безнең ата-бабалар бу «фән»не гомер барышында шактый камил дәрәҗәдә үзләштергән булганнар. Әлеге ярым мифологик, ярым фәнни фаразлар (диагноз) системасы халык медицинасында, имчеләр, дәвачылар практикасында күптән җиренә җиткезеп эшләп куелган булган. Бүгенге көндә дә кайбер табибларның, авыруларга диагноз куйганда, өстәмә дәлил рәвешендә, кыяфәтнамә юрамышларын шактый җитди дәрәҗәдә өйрәнүләре һәм куллланулары хакында ишетергә, күрергә мөмкин. Чөнки борынгы заманнарда ук кешенең кыяфәтенә карап, авыртуны юраучы (чынлыкта диагноз куючы) кешеләр булган. Мәсәлән, борын белән бәйле медицина фаразлары аеруча күп. *"Борын сырты тар – үпкәсе авырып җәфалана", " Кысылган борын яки «кылыч борын» – организмда кальций алмашы бозык, умыртка баганасы авырта", "Киң борын – полип бар", "Борын «итек» рәвешле – йөрәк һәм кан тамырлары авыру, нервысы какшаган", "Борын салкынга сизгер булса, өшеп, кызарып торса – организмда тоз күбәйгән"* һ.б. Шуны да искәртергә кирәк: кеше борынының нинди төстә булуы да аның организмындагы процесслар хакында сөйли дип фаразлыйлар. Шундый фаразларның медицина тарафыннан расланган, дәлилләнгән берничәсе: *"Борын очы кызару – капиллярлар киңәюне, кан басымы күтәрелүне, ашказаны-эчәк эшчәнлеге бозылуны, шулай ук күзәнәкләр яралу сәләте бозылу"ны белдерә. "Борын очы шәмәхә төскә керсә – йөрәк тибүе бозылган, кан басымы түбәнәйгән, капиллярлар киңәйгән һәм кан тамырлары эшчәнлеге сүлпәнәйгән", "Ак борын – капиллярлар кысылу нәтиҗәсе".*

Чәчләрнең төсе дә, хәләте дә кешенең сәламәтлеге, организмдагы җитешсезлекләр турында сөйли. Чәчләр белән бәйле медицина фаразлары: *"Җирән чәч – буыннары ревматизм белән җәфалана", "Чәч коелу, чәчнең очлары теткәләнү, яргалану – шикәрле ризыкларны күп ашау яисә артык ашау нәтиҗәсе", "Кыл кебек каты,*

*ак чәч – баш авыртучанлык билгесе", "Чәчнең иртә һәм тиз агаруы – бавырда, үт куыгында авыру хасил булу", " Чәч кору-кавыклану – ашказан асты бизе авыруы", "Кавык – майлы ризыклар һәм аксым белән артык мавыгу нәтиҗәсе".*

Авыз һәм иреннәр исә организмда ризык эшкәртелү процессын күрсәтә. Мәсәлән, *"Авыз кысып ябылган – бавыр, бөер, үт куыгы борчый. Организмда тоз күп", "Авыз ярымачык – сулыш юллары, ашказаны – эчәк борчый".*

Шул рәвешле, кеше тәнендәге һәр әгъза, аның кыяфәтендәге һәр чалым, төс, рәвеш организмның хәзерге рухи-психологик хәле, сәламәтлекнең бүгенге торышы хакында хәбәр итә һәм вакытында дәваланырга этәргеч бирә. Халкыбызның мифологик хәтерендә сакланып калган бу мирасны кабат торгызырга, өйрәнергә һәм көндәлек тормышыбызга кайтарырга кирәктер.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: юрауларның кеше тормышына йогынтысы зур. Юрау – ышануларга ышану-ышанмау – һәркемнең үз эше, билгеле.

**Әдәбият**


1. Татар мифлары: ияләр,ышанулар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 432 б.
2. Татар халык иҗаты: мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 386 б.
3. Шәрипова Ш. С. Кеше – сәламәтлек – ислам. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 206 б.

# ХӘЗЕРГЕ БАШКОРТ ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫНДА ЯҢА АЛЫНМА СҮЗЛӘР

*Салаватуллина А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Кириллова З.Н.*

Телләрнең үзара мөнәсәбәткә керү үзенчәлекләре һәм аларга бәйле күренешләр, аерым алганда, билгеле бер телдән башка телгә алынмалар үтеп керү процессын тикшерү гомуми тел белемендә шактый әһәмияткә ия һәм әлеге үзенчәлекләрне өйрәнү тарихы бик зур. Бу мәсьәлә хәзерге вакытта бигрәк тә актуаль һәм ул шактый тел галимнәренең игътибарын җәлеп итәргә мәҗбүр, чөнки бу XX гасыр ахыры һәм XXI гасыр башындагы халыкара элемтәләрнең артуы һәм тел элемтәләренең ныклыгы белән характерлана. Шушы күренешләр халык арасында һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә дә бара [1: 112].

Башкортстан Республикасында хәзерге тел ситуациясенең үзенчәлеге итеп интеграцион процессларның активлашуын санарга мөмкин, чөнки алынмалар лексик дәрәҗәдә ачык чагылыш таба. Шуңа бәйле рәвештә, башкорт теленең яңалыкларны кабул итүгә карата тотрыклылыгы турындагы мәсьәлә белән бәйле лингвистик бәйләнешләр проблемасы да актуаль булып кала бирә.

Фәнни эшнең **максаты** – башкорт телендәге вакытлы матбугатта алынмаларның урынын, ролен барлау һәм аларны тематик төркемнәргә туплау. Бирелгән максатка ирешү өчен, темага караган теоретик материал белән танышу, алынмаларның телгә үтеп керү сәбәпләрен ачыклау, вакытлы матбугатның 2020-2022 нче елларда басылган саннарындагы яңа алынмаларны туплау эше үткәрелде. Тикшеренүләрнең нигезен башкорт басма матбугатында соңгы 2023 ел эчендә басылып чыккан газета-журналлар (“Киске Өфе”, “Йәшлек”, “Башҡортстан” газеталарында, “Ағиҙел”, “Аманат”, “Башҡортстан ҡыҙы” журналлары) тәшкил итә.

Хәзерге башкорт теле өчен хас булган үзгәрешләр аның лексик составында чагылыш таба. Бу фәнни-техник прогресс, илдә демократик җәмгыятьнең барлыкка килүе белән бәйле, ул җәмгыятьнең матди һәм рухи тормышка бәйле барлык өлкәләренә дә сизелерлек йогынты ясый. Гарипов Т.М. билгеләвенчә, “Рус теле һәм башкорт теле үзара мөнәсәбәткә кергәннән соң, рус теленең башкорт теленә йогынтысы зуррак була” [2: 273].

Соңгы елларда башкорт матбугатында очрый торган бер төркем рус-европа алынмаларын *семантик неологизмнар* исәбенә кертеп карыйлар. Мәсәлән, узган гасырның 90 нчы елларында аеруча актив

булган *демократия* термины илдәге сәяси режимны белдерсә, хәзерге заманда исә аның мәгънәсе киңрәк: ***демократия*** – коллектив эшчәнлекне оештыру принцибы, нинди дә булса иҗтимагый төркемдәге барлык әгъзаларының актив, тигез хокуклы катнашуы. ***Кондиционер*** сүзен барыбыз да биналарда оптималь климат шартларын тәэмин итү җайланмасы буларак аңлыйбыз. Бүгенге көндә сүзнең мәгънәсе киңрәк: ***кондиционер*** – чәчләрне йомшаграк итүче косметик чара [3: 56]. Моңа мисаллар карап үтик: *Хәҙерге донъяла* ***демократия*** *сәйәсәттә генә түгел, ғаилә мөнәсәбәттәрендә лә мөһим*; ***Кондиционер*** *ҡулланһаң, сәс буяу бик үк ҡурҡыныс түгел*.

Башкорт вакытлы матбугатында алынмаларның турыдан-туры тәрҗемә ителгән очраклары, ягъни калькалар еш очрый: "***Матурлыҡ салоны*** *булғаҫ, үҙенең күҙаллауынса, матур нисек була, шулай яһап сығаралар, тип өмөт итә бит ул*"; "*РФ Хөкүмәте* ***"әсәлек капиталы"н*** *айлыҡ түләүҙәргә тотоноу тәртибен раҫланы*"; "*Яңы уҡыу йылына Хәйбулла һәм Учалы райондарында ике яңы* ***полилингваль мәктәп*** *асыласаҡ,* ***капиталь ремонттан*** *һуң Мишкә районында һәм Сибайҙағы мәктәптәр ошо юнәлештә эшләй башлаясаҡ*".

Башкорт вакытлы матбугатында рус теленнән кергән кушма сүзләрне дә тәрҗемә итү тәҗрибәсе бар: "*Бында видеокүҙәтеү камералары ҡуйылған, амфитеатр урнаштырылырға тиеш*"; *Балалар менән ватсаптан видеошалтырату аша һөйләштек*. Шул ук вакытта билгеләнгән сүз калькалар исәбенә дә кертеп карала.

Без башкорт вакытлы матбугатында чагылыш тапкан рус-европа алынмаларын тематик төркемнәргә бүлеп тикшердек һәм түбәндәгеләрне аерып чыгара алдык: уку-укыту, белем бирү белән бәйле рус-европа алынмалары (*мастер-класс, воркшоп, вожатый, тренинг, коучинг*), Интернет челтәре белән бәйле алынмалар (*компьютер программалары, мобиль ҡушымталар, платформа, цифрлы платформалар, маркетплейс*), кием-салым атамалары (*карго, кроп-топ, футболка, худи, кроссовки*), бизәнү әйберләрен аңлаткан алынмалар (*аксессуар, каф, чокер, орнамент*), һөнәрләр (*программист, таксист, водитель*), аш-су, ризык атамалары (*вафля, шоколад, пломбир, эскимо*), спорт өлкәсенә караган рус-европа алынмалары (*кикбоксинг, айкидо, шахмат, сурдлимпия, атлетика, дзю-до*), кешенең организмы, сәламәтлеге белән бәйле рус-европа алынмалары (*медицина, организм, нервы системаһы, аллергия, антигистамин*). Димәк, башкорт вакытлы матбугатында рус-европа алынмалары шактый киң урынны били дигән нәтиҗәгә килә алабыз.

Шулай итеп, хәзерге башкорт теле өчен хас булган үзгәрешләр аның лексик катламында аеруча да зур чагылыш таба. Бу, беренче чиратта, фәнни-техник прогресс, илдә демократик җәмгыятьнең барлыкка килүе белән бәйле. Әлеге күренешләр җәмгыятьнең матди һәм рухи тормышка бәйле барлык өлкәләренә дә сизелерлек тәэсир итә. Без моны тикшеренүләрдән чыгып дәлилли алдык.

Статистик яктан нәтиҗә ясаганда, хәзерге башкорт телендә Интернет челтәре (28%), белем бирү белән бәйле (17%), кием-салым атамаларын аңлаткан рус-европа алынмаларының (13%) башка тематик төркемнәргә караганда күбрәк булуын ачыкладык. “Киске Өфе”, “Йәшлек”, “Башҡортстан” газеталарын, “Ағиҙел”, “Аманат”, “Башҡортстан ҡыҙы” чыганакларын тикшергәндә, алынмаларга иң бай газета “Киске Өфе” булуы ачыкланды (57%).

Хезмәтебезне башлар алдыннан, башкорт телендәге вакытлы матбугатта алынмаларның урынын һәм ролен барлау һәм аларны тематик төркемнәргә туплап өйрәнүне максат итеп куйган идек. Максатыбызга ирештек дип саныйбыз һәм алга таба әлеге теманы тагын да тирәнрәк өйрәнергә исәплибез.

**Әдәбият**

1. Брайант Д. Основы воздействия СМИ. – М.: Вильямс, 2001. – 233 с.

2. Гарипов Т.М., Емалетдинов Ф.Д., Емалетдинова З.А. Краткий русско-башкирский словарь иноязычных заимствований. – Уфа: Вагант, 2006. – 361 с.

3. Закирьянов К.З. Сопоставительная типология русского и башкирского языков. Фонетика, лексика и фразеология. – Уфа: РИО БашГУ, 2002. – 212 с.

# ИСКЛЮЧИТЕЛЬНЫЕ СУЩЕСТВИТЕЛЬНЫЕ НА СОВРЕМЕННОМ ИВРИТЕ

*Сафарова Г., аспирант Национальной Академии Наук Азербайджана, Институт Истории им. Аббасгулу Ага Бакиханова*

На иврите это существительное называется «шем эцем» и буквально переводится как «название вещи». На иврите существительные изменяются не только по количеству, но и по роду. То есть, чтобы классифицировать существительные по роду и количеству, необходимо знать категорию рода [4: 7-10]. В иврите существительные делятся на две родовые категории: женский и мужской. Есть 4 окончания, указывающие на то, что существительное женского рода [1]:**ָה (каматс ҳэй). ת ֶ ֶ (е-е-т). ית (и-т). ות (у-т)**

Если какое-либо существительное в единственном числе оканчивается на любое из этих окончаний, то это существительное считается женского рода [3: 12-15]. Например, *מוֹרָה, תַּלְמִידָה, כִּתָּה, הַצָּגָה*. Произношение: Мора, талмида, кита, хацага. Перевод: Учитель, ученик, класс, выступление. *מִרְפֶּסֶת, דֶּלֶת, מַחְבֶּרֶת*. Произношение: Мирпесет, делет, махберет. Перевод: Балкон, дверь, тетрадь. *מְכוֹנִית,* *שַׂחְקָנִית, גְּרָפִיקָאִית*Произношение: мехонит, сахканит, графикаит. Перевод: Машина, актриса, графический архитектор. *תַּרְבּוּת, חֲנוּת, יַלְדוּת* . Произношение: Тарбут, ханут, ялдут. Перевод: Культура, магазин, детство.

Определенной концовки в этом направлении нет, то есть, кроме 4-х перечисленных выше концовок, все остальные окончания указывают на мужской пол. Например,*סֵפֶר, תַּלְמִיד, מוֹרֶה, חָבֵר*. ***Произношение:*** *Сефер, талмид, море, хавер.* ***Перевод:*** *Книга, ученик, учитель, друг (участник)* [6: 3-6].

Г.О.Винокур: «Тіл қарым-қатынас құралы болумен қатар, ол күрделене келе поэтикалық сапаға ауысады» [2:16], – дейді. Сонымен поэтиканың негізгі қарастыратын нысаны – жазушының, не ақынның көркем шығармасындағы идеялық концепциясы мен оның шығармашылық лабораториясында пайдаланған әдіс-тәсілдерінің жүйесі, диалектикалық бірлігі мен байланысы болып табылады. Ал В.Жирмунский поэтиканың ауқымын өте кең ала отырып былай анықтама береді: «...шын мәнінде көркем шығарманың құрылымында барлық амал-тәсілдер бір-біріне ықпал етіп, бір көркемдік мақсатқа бағындырылады. Поэтикалық шығармада осы тәсілдердің бірлігін біз «стиль» дейміз» [3:35].

Осы орайда әдебиетімізге өзіндік қолтаңбасымен келген қаламгер Талғат Кеңесбаевтың шығармашылық жаңалығы, өзіндік үні, әлем әдебиетімен иық тірестіре алатын келбетімен өлшенеді деп айта аламыз. Талғат Кеңесбаев – қазіргі қазақ прозасындағы танымал жазушы. Талғат Кеңесбаевтың көпшілікке белгілі шығармалары – «Француз әтірінің иісі», «Гауһар», «Ұлу жылы», «Ақ марқа» повестері. Бұлар классикалық шығармаға айналған, уақыт жылжыған сайын жаңа ұрпақ – жас буынмен үндесіп, оқыла беретін нағыз жаңашыл хикаяттар. Жазушының көбірек қалам тартқан жанры – әңгіме. Оның

кез келген әңгімесі жинақы, шағын болғанымен көтерген проблемасы күрделі. Жазушы шығармаларының тіл көркемдігі де ерекше. Мысалы:

*Күнді түн жұтты. Ай қашып, жұлым-жұлым қара кебін ішін кезіп кетті. Тоқтамайды толған ай. Нені іздейді? Жұлдыздарды ма? Тұнық түнгі аспанды ма? Жоқ әлде...* («Қанден» әңгімесінен). Бұл мысалда прозалық шығармада табиғатты көркем шеберлікпен поэзия тіліне ұқсатып суреттеген. Қаламгер қолданған теңеулер де ерекше. Суреткердің бір ерекшелігі – кейіпкердің ішкі жан дүниесіне, оның мінезіне, ирімінің қалтарыс-бұлтарысына зер сала үңіледі. Мысалы:

*Ертістің жон арқасы көкпеңбек. Құс қанатындай сусылдап ағып барады. Езуі ақ көбік. Аяғыма балдыр жабысты. Тіземнен суды кешіп бардым. Қатты ағын теңселтіп жіберді. Басым айналды. "Аман бол, Ертісімнің алтын балығы". Алақанымдағы балық шолп етіп суға түсті... Балағымнан су сорғалап, жағаға шықтым.*

*– Папа, неге жібердің суға, балалардың бәріне алтын балығым бар деп айттым. Енді мені өтірікші дейді ғой, - иығы селк-селк етті.*

*– Ұлым-ау, ұлым...* («Қасқалдақтың қаны» әңгімесінен).

Бір шағын отбасының тіршілігі арқау болған осынау шағын әңгімеде тіршілігі ауыр, бейнет-тауқыметі мол тағдырлар көрініс береді. Тағы бір әңгімесі "Үйірін табар ма екен?", осы шағын әңгімесінде романға арқау болар сюжет бар. Бірақ әдеби шеберлігі шыңдалған жазушы осы қысқа ғана шығармасымен ақ әлемдік проблеманы қысқа ғана қайыра салған екен.

*«Енді-енді босаға жұлдыз төмендеп, айналайын Күн-Ана көтерілерде шығыстан, қытай жақтан жарылыс үні шығатын болды».* Бұл тек Семей жұртының қан жұтқан проблемасы емес, жалпы адамзаттың басына төнген қатер еді. Шыңғыстау бауырындағы алапат жарылыс, полигон зардабы – әңгімедегі негізгі идея.

«*Сенде тудым, сенде өлсем арманым не, Шыңғыстау. Бәрін де сеземін, бәрін де білемін. Дегелең жақтан қара құйын көтерілген кезде омыртқаңды опырып, жұлыныңды суырардай қиналасың қара нарым..!»*

Т.Кеңесбаев шығармаларының дені әлеуметтік бағыттағы проблемаларды көтереді. Қаламгер әңгімелерінде отбасы конфликті, өмірден баз кешкен адамның жай-күйі, өмірден өз орнын таба алмаған жанның қасіреті, жетім мен жесір трагедиясы, адамдық, адалдық... бәрі қамтылған. Талғат Кеңесбаев шығармаларында тарихи тақырып та кездеседі. Солардың бірі жазушының тарихи тақырыптағы алғашқы көлемді дүниесі – тәуелсіздік идеясы мен ұлттық сананы қалыптастыратын «Қараңғы түннің жұлдызы» шығармасы (Зуқа батыр Сәбитұлы) хикаяты. Жазушының көркем шығармаларынан тарихи

өмірдің сәулелі сәттерінің сан қилы құбылыстарын көреміз. Кеңесбаев әңгімелерінің көркемдік-поэтикалық арнасы мүлде бөлек. Оның шығармаларын оқи отырып, кейіпкерлерімен бірге образға еніп, сол баяндалған оқиға ішінде жүргендей боласың. Бұл қаламгердің шеберлігін көрсетеді, шығармаларына үлкен әлеуметтік, тарихи мәселелерді арқау етуінен. Сонымен қатар осы күрделі мәселелерді оқырман жүрегіне жеткізе білу де жазушыдан асқан шеберлікті, көркем тілді қажет ететіні даусыз. Қаламгер осы талаптардың үддесінен шыға білген.

**Әдебиет**

1. Потебня А. Теоретическая поэтика. – М.: Высшая школа, 1990. – 342 с.

2. Винокур Г.О. Филологические исследования. – М.: Наука, 1990. – 447 с.

3. Жирмунский В.М. Теория литературы. Поэтика. Стилистика. – Ленинград: Наука, 1977. – 404 с.

4. Виноградов В.В. Стилистика. Теория поэтической речи. Поэтика. – М.: АН СССР, 1963. – 380 с.

# СПЕЦИФИКА НЕВЕРБАЛЬНОЙ КОММУНИКАЦИИ

*Тимербаев И., КФУ, магистрант I курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Нурмухаметова Р.С.*

Невербальный язык применялся еще с древних времен. Вопросы, связанные с данным видом общения по сей день остаются крайне актуальными. Многие компоненты невербальной коммуникации закрепились в национальных традициях, культуре тюркских народов и в течение длительного времени функционируют в жизнедеятельности общества. Впоследствии они стали константами (укоренившимися элементами) языковой картины мира. Данные элементы переходили в словесный язык, лексическую структуру языка, закрепившись в культуре народа. Они крайне важны для социальной коммуникации.

Невербальная коммуникация – это общение людей без использования слов, письменной и устной речи, это компонент эмоций, внешняя форма их существования и проявления. По В.П. Морозову невербальное общение отличается от вербальной лингвистической коммуникации следующими характеристиками: полисенсорная природа, т. е. реализация одновременно через разные органы чувств (слух, зрение, обоняние и др.); историческая древность по сравнению с вербальной речью; независимость от семантики речи (слова могут значить одно, а интонация голоса – другое); значительная непроизвольность и подсознательность; независимость от языковых барьеров; особенности акустических средств кодирования; особенности психофизиологических механизмов восприятия (декодирование мозгом) [2: 21].

Определено, что в роли постоянных выступают лишь экспрессивные коды основных эмоциональных состояний человека: радости, страха, гнева, внимания, удивления, презрения и др. Прочие методы невербального кодирования зависят от большого числа различных факторов. Среди них: общая ситуация общения; индивидуальные особенности проявления состояний каждым из участников общения; пол; возраст; степень значимости собеседников друг для друга; культурные и этнические нормы выражения индивидуальных особенностей личности.

Важно также затронуть семиотику. Она изучает знаковые системы. Именно семиотика занимается исследованием трансформации невербальных компонентов в лексическую структуру языка (лексический код). Особенно весомыми работами в области семиотики являются труды Г.Е. Крейдлина.

Г.Е. Крейдлин в своем труде [1] разделяет невербальную коммуникацию на 10 частных разделов, из которых формируется невербальная семиотика:

1. Паралингвистика (просодика).

2. Кинесика (наука о жестах и жестовых движениях, о жестовых процессах и жестовых системах).

3. Окулесика (наука о языке глаз и визуальном поведении людей во время общения).

4. Аускультация (наука о слуховом восприятии звуков и аудиальном поведении людей в процессе коммуникации).

5. Гаптика (наука о языке касаний и тактильной коммуникации).

6. Гастика (наука о знаковых и коммуникативных функциях пищи и напитков, о приеме пищи, о культурных и коммуникативных функциях снадобий и угощений).

7. Ольфакция (наука о языке запахов, смыслах, передаваемых с помощью запахов, и роли запахов в коммуникации).

8. Проксемика (наука о пространстве коммуникации, его структуре и функциях).

9. Хронемика (наука о времени коммуникации, о его структурных, семиотических и культурных функциях).

10. Системология (наука о системах объектов, каковыми люди окружают свой мир, о функциях и смыслах, которые эти объекты выражают в процессе коммуникации) [1: 22].

Несмотря на то, что в настоящее время есть много работ по данной тематике, остается недостаточно изученным вопрос о языковом отражении невербального поведения в культуре тюркских народов. На основании вышеизложенного можно сделать вывод, что целесообразным будет более детальное изучение области лексики, относящейся к невербальной коммуникации. Это обусловлено значимостью для формирования у людей, исследующих традиции и языки тюркских народов, навыков невербального общения и подробного изучения коммуникативной культуры.

**Литература**

1. Крейдлин Г.Е. Невербальная семиотика: Язык тела и естественный язык. – М.: Новое литературное обозрение, 2002. – 592 с.

2. Морозов В.П. Невербальная коммуникация: Экспериментально-психологические исследования. – М.: Изд-во «Институт психологии РАН», 2011. – 528 с.

ЯШЬЛӘР ТЕЛЕН АҢЛЫЙСЫЗМЫ?

*Тимофеева В., 131нче лицей, IX сыйныф*
*Фән. җит. Айнуллова Г. Н., Шәйхуллина Л.К.*

Татар теленең яшәеше һәм аның киләчәге турында уйлансак, беренче чиратта, телебезнең көндәлек аралашу үзенчәлекләренә игътибар итәргә кирәк. Чөнки нәкъ менә сөйләм теле, аның яшәеш формалары тел үсешенә зур йогынты ясый да инде. Бүген күпләр замана яшьләренең сөйләмен аңлап җиткерми. Ул әдәби тел нормаларына якын тормый. Замана яшьләренең сүз байлыгы шулкадәр тиз үзгәреп, үсеп тора ки, әгәр шушы мохиттә кайнап яшәмәсәң, бу лексиканы аңлап, өйрәнеп бетерәм димә.

Соңгы елларда җәмгыятьтә телләр кулланышында шактый иркенлек, әдәби тел нормаларының сакланмавы, әдәби телгә куелган таләпләрнең үтәлмәве күзәтелә. Моңарча җәмгыятьне күп татар яшьләренең рус һәм татар телләрен кушып сөйләшү проблемасы борчыса, хәзер аларның сөйләше инглиз теленә охшап кала.

Эшнең гомуми максаты – «Яшьләр сөйләме». Бу тема бүгенге көндә дә актуаль, чөнки яңа замандагы сөйләмдә кулланылган, яшьләрнең сөйләмен серле иткән заманча сленглар актив кулланыла һәм популярлаша. Дөрестән дә, яшьләр ниндидер колакка ятышсыз сүзләр куллана кебек. Мин – яшь буынның бер вәкиле буларак шул аңлаешсыз сүзләргә аңлатма бирергә телим. Күпләр хәзерге замана яшьләренең сөйләшү стилен аңламый. Дөрестән дә, яшьләр ниндидер колакка ятышсыз сүзләр куллана кебек.

СЛЕНГ – инглиз теленнән безнең телгә калькалаштыру юлы белән кабул ителгән сүз. Термин буларак «slang» сүзе XIX гасырдан бирле актив кулланышта, ә аның беренче тапкыр лексикага килеп керүе XVIII гасыр урталарына карый. Башта ул гади һәм шикле сүзләр сүзлеге буларак аңлатылган. Соңыннан аңа тулаем оешкан фәнни билгеләмә бирелгән. Сленг (slang) – төрле яшьтәге кешеләр, төрле социаль катламнар, төрле һөнәр ияләре куллана торган, моңарчы башкача аталган сүзләрнең заманчалаштырылган варианты.

Гомумән, соңгы елларда җәмгыятьтә телләр кулланышында шактый иркенлек, әдәби тел нормаларының сакланмавы, әдәби телгә куелган таләпләрнең үтәлмәве күзәтелә. Моңарчы җәмгыятьне татар яшьләренең рус һәм татар телләрен кушып сөйләшү проблемасы борчыса, хәзер аларның сөйләше инглиз теленә охшап кала. Шушы ук хәл кайбер һөнәр ияләренең телләрендә дә чагыла. Бу күренеш – «сленг» дип атала. Ә хәзер исә моңа караш башкачарак. Киресенчә, күп кенә югары белемле, абруйлы кешеләр үзләре кайнаган профессиональ

яисә дустанә мохитләрендә сленглар, жаргоннар кулланып сөйләшә. Чөнки бу сүзләр сөйләмне озын катлаулы терминнардан арындыра, билгеле бер социаль группа өчен күпкә аңлаешлырак итә.

Сленглар кулланып сөйләшүнең сәбәпләре күп төрле. Сораштыру шуларны күрсәтә:

- уңайлы, кыска;
-мода шундый, сленг куллану - «текә», заманча;
- сөйләмгә эмоциональлек , җанлылык өсти;
- юморны арттыру нисбәтеннән кулланыла;
- әдәби сүз байлыгы зур булмаса, сленг- сүзләр ярдәмгә килә;
- билгеле бер төркем, компания өчен аңлаешлы;
- сөйләмдәге кимчелекләрне капларга ярдәм итә;
- башкалар арасында аерылып торасың һ.б.

Статистикага күз салсак, Русиядә яшәүчеләрнең 66 проценты – профессиональ, 54 проценты – интернет сленгы белән сөйләшә. Яшьләр сленгы – 79 процент кулланылышта.

Нәтиҗәдә, бүгенге үсмерләр сөйләмендәге сленг тотрыклы һәм актив рәвештә үсүче күренеш булып тора.

Моннан чыгу юллары нинди соң? Үсеп килүче буын шуны белергә тиеш: Русиядә дөрес һәм төзек сөйләшә белү – модадан калышмауны һәм кешенең белемле, укымышлы булуын күрсәтә. Хәзерге үсмер киләчәктә кирәкле кеше булырга теләсә, ул үзенең сөйләм культурасын формалаштырырга, күбрәк укырга, фикерләргә, үз фикерен яклап бәхәскә керә белергә тиеш.

Әлбәттә, без сленгларны актив лексикага кертү ягында түгел. Шулай булса да, дөньякүләм барган процесслардан без бөтенләй азат түгел. Укучыларны үз туган телебез сагына басарга чакырабыз. Төрле шаукымнарга ияреп, гомумән телсез, туган илсез калмыйк. Телебез язмышы да, милләтебез язмышы да, матур киләчәгебез дә – үз кулыбызда.

Гомумән, тел үсешен җәмгыять билгели, димәк, тел хәзинәсен саклау – бүгенге көндә хәл ителмәгән проблема булып кала.

Бу эш дәвамында замана яшьләренең тел үзенчәлекләрен өйрәнеп, сәбәпләрен ачыкладык, ягъни үзебезнең максатка ирештек.

**Әдәбият**

1. Даль В.И. Толковый словарь живого великорусского языка. – М., 1956.

2. Стенин И.А. Словарь молодёжного жаргона. – Воронеж, 2004.

3. Горбачевич К.С. Особенности молодёжного жаргона // РЯШ. – 2001.

4. Запесоцкий А.С. Эта непонятная молодёжь. – М., 1998.

# МАҚАЛ-МӘТЕЛДЕРДЕГІ ПАРЕМИОЛОГИЯЛЫҚ ЭКВИВАЛЕНТТІЛІК МӘСЕЛЕЛЕРІ

*Токенова Д., «Тұран Астана» университеті, I курс магистранты,*
*Қазақстан Республикасы, Астана қаласы*
*Ғыл. жет. – филол. ғыл. канд. Донбаева А.Б.*

Мақал-мәтел – халықтың қоғамдық құбылыстарды кең қамтып, өмірдегі әр қилы қарым-қатынастарды әсерлі, көркем бейнелейтін, тақырыбы, идеялық мазмұны бай ең бір мол саласы. Мақал-мәтел – халықтың нақыл сөздері, белгілі бір ойды ықшамды түрде ұтымды, өткір етіп «Мақал»сөзі араб тілінен енген кірме сөз, негізгі мағынасы "орынды сөз" деген ұғымды білдіреді.

Тілдің паремиологиялық қорында этностың өзіне тән қасиеттері сақталады. Тіл халықтың қоғамдық, әлеуметтік өмірімен, саяси-экономикалық жағдайымен тығыз байланыста дамиды, кемелденеді. Тілдің лексикалық құрамының бөлінбес бір сыңары саналатын мақал-мәтелдер ұлт тілінің ғана емес, ұлт мәдениетінің де көрсеткіші болып табылады. Тілдің байлығы, сұлулығы және өткірлігі бір халықтың мәдени мұрасы болып табылатын мақал-мәтелдерде анық көрініс табады. Мақал-мәтелдер арқылы айтайын деген ойыңды ықшам, әрі ұтымды жеткізуге болады. Сондықтан мақал-мәтелдердің өн бойынан поэзияға тән жинақылық, үнділік, саздылық, ұйқас ырғақты кездестіреміз. Сонымен қатар, мақал-мәтелдерден халықтардың дүниетанымы, ұлттық ерекше ойлау жүйесі аңғарылады.

Ахмет Байтұрсынов: "Мәтел дегеніміз – кезі келгенде кесегімен айтылатын белгілі-белгілі сөздер. Мәтел мақалға жақын болады. Бірақ мақал тәжірибеден шыққан ақиқат түрінде айтылады", − деп мақал мен мәтелдің ара-жігін ажыратып берген [2: 250].

Мақал-мәтелдер қазақ халқының «ментальды» айнасы, халық санасының көрінісі болып табылады. Мақал-мәтелдерден халықтың дүниетанымы, тарихы, салт-дәстүрі, тұрмыс-тіршілігі туралы құнды ақпарат алуға болады. Сондай-ақ, мақал-мәтелдер ықшамдылығымен, мағынасының тереңдігімен және тілінің өткірлігімен ерекшеленеді. Сондықтан аталарымыз «тоқсан ауыз сөздің тобықтай түйінін» жеткізу үшін әрдайым фольклорымыздың теңдесіз қазынасы мақал-мәтелдерге жүгінген.

К. Ахановтың пікірінше: "Мақалдар көбінесе екі бөлімді болып келеді де, алдыңғысында шарт немесе жалпы пайымдау, соңғысында қорытынды түйінді пікір айтылады", – деген пікір айтады [2: 177].

Ә.Т.Қайдаров мақал-мәтелдер жайында «Көркем сөз тәсілдерінің ішіндегі қуаттысы мен құнарлысы болып саналатын

мақал-мәтелдер – тіл атаулының баршасына тән, өзіндік ерекшелігімен көзге түсетін әмбебап құбылыс» - деп тұжырым жасайды [3:1].

Мақал-мәтелдер кез келген тілде бар. Әр түрлі тілдерде мақал мәтелдердің мағыналық жағынан ұқсас эквиваленттері кездесіп отырады. Мысалы, қазақ тіліндегі: «Ештен кеш жақсы» деген мақал туыстас түрік тілінде: «Hiçten geç yeğdir» болып айтылады. Сол сияқты, қазақшада:«Жақсы әйел жаман еркекті адам етеді». Түрікше:«Kadın Kocasını isterse vezir isterse rezil eder».

Туыстас емес ітледред де мақал мәтелдердің эквиваленттілігі ұшырасады. Мысал қазақ тіліндегі көптеген мақал мәтелдердің орыс тіліндегі баламаларын таба аламыз: *Еңбек етсең – емерсің.*

*Еңбек етсең ерінбей, тояды қарның тілінбей.*

*Еңбегіне қарай өңбегі.*

*Бейнетің қатты болса, татқаның тәтті болар.*

*Істесең, тістерсің.*

*Қол ойнағанның аузы ойнар.*

*Ексең егін, ішерсің тегін.* Осы мысалдарға эквивалент бола алатын мақалдар:

1. *Хочешь есть калачи, так не сиди на печи!*
2. *Без труда не вынешь и рыбку из пруда*
3. *Любишь кататься, люби и саночки возить.*
4. *Без труда нет плода.*
5. *Кто хочет съесть орешек, тот должен сломать скорлупу.*
6. *Кто хочет рыбку съесть, тот должен в воду лезть.*

Мәтелдің мақалдан басты айырмашылығы – ықшамдылығы мен қысқалығы, тұжырымының тиянақталмауы. Мәтел сөз арасында айтылып сөзді жандандыра түседі, тілге ерекше көрік береді, айтылмыш пікірді қуаттап нықтайды. Мәтел, сонымен қатар толық сөйлем ретінде де кездесе береді. Мақал толық тұлғалы болады, ойы тұтас келеді, әдетте, ол бір немесе бірнеше толық сөйлемнен құралады.

Мақал бір, екі, кейде төрт сөйлемнен құралады. Мысалы; Өз үйім – өлең төсегім; Өзге елде сұлтан болғанша, өз еліңде ұлтан бол. Жаманнан жақсы туды деп сүйінбе, Ол да тартар негізге. Жақсыдан жаман туды деп күйінбе, Ол да тартар негізге. Қай халықта болмасын мақал әрқашан толық сөйлем күйінде келеді: «Достың алыс-жақынын іс түскенде білерсің». Қазақ және ағылшын мақалдарының ішінде үш тармақты, төрт тармақты түрлері де кездеседі. Мысалы: «Кеспе көже күн батқанша, Бидай көже ел жатқанша, Тары көже таң атқанша». Байлауы жоқ шешеннен, Үндемеген есті артық. Бәйге алмаған жүйріктен Белі жуан бесті артық; «Үйдің жылы-суығын, Қыс түскенде білерсің. Достың алыс-жақынын, Іс түскенде білерсің».

Мақал дегеніміз – халықтың ғасырлар бойы жинақтаған өмір тәжірибесінің бір ауыз сөзбен берілген қорытындысы, түйіні. Мақал белгілі бір ұғымды тікелей білдірсе, мәтел жанамалап, меңзеп, тұспалдап жеткізеді. Мақалда айтылар ой тура не астарлап айтылады. Мақал-мәтелдердің авторы болмайды, нақыл сөздердің, қанатты сөздердің авторы болады. Мақал-мәтелдердің шешендік сөз үлгісіне қарағанда мазмұны жалпы болады. Мақал-мәтелдер өзге тұрақты сөз орамдарынан (қанатты сөз, т.б.) тұлға жағынан ықшам, мазмұн жағынан әмбебап болады.

**Әдебиет**

1 Байтұрсынов А. Шығармалар жинағы. – Алматы, 1989.

2 Қайдаров Ә., Тұрабаева Ғ. Қазақ мақал-мәтелдері мен авторлық-стильдік инварианттары жайында // ҒА Хабарлары. Тіл сериясы, №3.

3 Аханов К. Тіл білімінің негіздері. – Алматы: Санат, 1993.

# ПЕСНЯ КАК МЕТОДИЧЕСКОЕ СРЕДСТВО ОБУЧЕНИЯ ИНОСТРАННЫМ ЯЗЫКАМ

*Фаляхова Р., КФУ, студент V курса*
*Науч. рук. – PhD, ст. преп. Гайнутдинова А.С.*

Обучение иностранному языку – это процесс, требующий творческого и инновационного подхода. Когда мы говорим о песне как об инструменте преподавания иностранного языка, мы обращаемся к использованию музыкальных композиций на целевом языке с целью улучшения способностей в языке у учащихся. Этот метод занимает важное место в процессе обучения, поскольку музыка активизирует слух и память, делая процесс усвоения новых фраз и выражений более естественным и запоминающимся.

Е.П. Каппинчекова отмечает, что музыка является одним из наиболее эффективных способов воздействия на чувства и эмоции школьников. Помимо этого песни являются неиссякаемым источником пассивной лексики, дают возможность ненавязчиво повторять грамматические явления изучаемого языка.

Методические преимущества (Гальскова Н.Д.)

- песни как один из видов речевого общения являются средством более прочного усвоения и расширения лексического запаса, так как включают новые слова и выражения.

- в песнях лучше усваиваются и активизируются грамматические конструкции. В некоторых странах издаются песни для обучения наиболее распространенным конструкциям.

- песни способствуют совершенствованию навыков иноязычного произношения, развитию музыкального слуха.

- песни содействуют эстетическому воспитанию учащихся, сплочению коллектива, более полному раскрытию творческих способностей каждого.

- песни и другие музыкальные произведения стимулируют монологические и диалогические высказывания, служат основой развития речемыслительной деятельности школьников, способствуют развитию как подготовленной, так и неподготовленной речи.

О.Е. Романовская предлагает следующие критерии отбор песенного материала:

1) музыкальный компонент: соответствие физиологическим особенностям голосового аппарата учащихся; яркая и запоминающаяся мелодия; наличие четкого ритма; соответствие этапу обучения;

2) поэтический компонент: художественная ценность произведения; соответствие психическим особенностям учащихся;

доступность языкового материала; наличие социокультурной информации; возможность использования при обучении различным аспектам языка и видам речевой деятельности; воспитательная ценность

Существует техника внедрения песенного материала в учебный процесс, и происходит это поэтапно. Трёхступенчатая модель, которая включает 3 этапа:

1) до прослушивания (вступительное слово о песне, об исполнителе, снятие трудностей, установка на прослушивание песни);

2)во время прослушивания (первое предъявление, контроль понимания, предъявление собственно текста песни, вторичное прослушивание, выполнение упражнений);

3) после прослушивания (выполнение упражнений на уровне содержания песни и её смысла, выполнение речевых упражнений по формированию лексических навыков, в которых песенный материал выступает в качестве стимула высказывания, заключительная работа с песней – ритмичное чтение текста или совместное пение)

В том числе выделяются следующие преимущества данного метода:

1. Песни развивают разнообразные языковые навыки, включая слуховое восприятие, разговорную практику, понимание текста, а также строение предложений и грамматику. Ученики активно усваивают новую лексику через прослушивание и повторение текстов песен. Через изучение и исполнение песен учащиеся совершенствуют свою произношение, интонацию и акцент, что делает усвоение речи более естественным и аутентичным.

2. Песни позволяют учащимся погрузиться в культуру и традиции стран, говорящих на изучаемом языке. Этот аспект обучения помогает учащимся получить более полное представление о языке и его социокультурном контексте, что способствует глубокому формированию лингвистического опыта и пониманию связи между языком и культурой.

3. Изучение языка через музыку вовлекает учащихся в процесс обучения, рождая у них аутентичный интерес к языку и культуре страны, говорящей на изучаемом языке. Эта методика не только вдохновляет учащихся изучать иностранный язык, но и помогает им приобщиться к его аутентичному использованию через обширный ассортимент музыкальных стилей, исполнителей и жанров.

Таким образом, песни являются мощным инструментом для обучения иностранному языку, который способствует развитию различных языковых навыков и углублению понимания культурного

контекста. Поэтому можно прийти к выводу, что использование песен в качестве метода преподавания иностранного языка представляет собой не только увлекательный, но и действенный подход, способствующий разностороннему и более глубокому усвоению языка и культуры.

**Литература**

1. Аль Азри Р.Х., Аль Рашди М.Х. Эффект использования аутентичных материалов в обучении // Международный журнал научных и технологических исследований. –2014. – №3. – С. 249– 253.

2. Гальскова Н.Д. Теория обучения иностранным языкам. – М.: Издательство Academia, 1996. – С. 324–334.

3. Каппинченкова Е.П. Роль музыки и песен в изучении иностранного языка // Иностранные языки в школе. –1995. – № 5. – С. 60-69.

4. Колкова М.К. Традиции и инновации в методике обучения иностранному языку. – СпБ: КАРО, 2007. – С. 41-53.

5.Романовская О.Е. Методика работы с музыкально-поэтическим фольклором в курсе обучения иностранному языку // Иностранные языки в школе. –2008. – №8. – С. 23-29.

ПОНЯТИЕ И ОСОБЕННОСТИ ГЕОМЕТИРЧЕСКОГО ДИСКУРСА АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА

*Фархуллина Г., КФУ, студент IV курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук. доц. Ашрапова А. Х.*

Дискурс – центральное понятие в лингвистике, обозначающее процесс вербального изложения сформулированных мыслей. Оно берет начало от термина “discursus”, означавшего беглый разговор или обсуждение. Со временем, термин приобрел значение рассуждения, довода или беседы.

Согласно исследованию, приведённой в работе Русаковой О. Ф. [3, с. 8], «дискурс предстает как совокупность текстов, порожденных в процессе коммуникации». Дискурс рассматривается как коммуникативное намерение в определенном контексте. Он включает в себя не только речевые высказывания, но и невербальные элементы коммуникации, такие как жесты, мимика и интонация. Дискурс может быть устным или письменным, а его структура и содержание зависят от различных факторов, таких как цель коммуникации, участники взаимодействия, социальный и культурный контекст.

Основная цель дискурса – передача информации, знаний, идей и эмоций. Он позволяет людям общаться друг с другом, обмениваться мыслями, переживаниями и знаниями. Дискурс также является инструментом для убеждения, обучения, информирования и развлечения.

В дискурсе выделяют несколько компонентов:

1. Текст – последовательность знаков, выражающая определенное сообщение. Текст может быть устным или письменным.

2. Контекст – ситуация, в которой происходит коммуникация. Контекст включает в себя физическое окружение, социальную и культурную обстановку, а также отношения между участниками общения.

3. Участники коммуникации – отправитель и получатель сообщения. Отправитель формулирует и передает сообщение, а получатель воспринимает и интерпретирует его.

4. Цель коммуникации – то, что отправитель хочет достичь с помощью сообщения. Цель может быть информативной, убеждающей, развлекательной или какой-либо другой.

5. Каналы коммуникации – средства, с помощью которых передается сообщение. Каналами коммуникации могут быть речь, письмо, жесты, мимика и другие средства.

Анализ дискурса – это изучение структуры и функций дискурса. Анализ дискурса может проводиться с использованием различных методов, таких как лингвистический анализ, социологический анализ, психологический анализ и другие.

Дискурс является важным объектом исследования в различных научных дисциплинах, таких как лингвистика, социология, психология, антропология и другие. Исследования дискурса позволяют глубже понять процессы коммуникации, социального взаимодействия и культурные особенности различных групп людей.

Геометрический дискурс английского языка в обучении учащихся представляет собой использование английского языка для передачи геометрических терминов и понятий в учебном процессе. Это не просто изучение геометрии на иностранном языке, но и развитие коммуникативных навыков учащихся в данной области. Основная цель такого обучения – овладение геометрическими понятиями и терминами на английском языке, а также умение воспроизводить их в речи в рамках учебной программы.

Интегрированное обучение, предполагающее преподавание предметов на иностранном языке, становится все более популярным в последние десятилетия. Такой подход позволяет не только изучать предметную область на английском языке, но и совершенствовать коммуникативные навыки учащихся в соответствующем дискурсе.

Однако необходимо учитывать, что уровень владения английским языком у учащихся в классе может быть разным. Поэтому важно проводить урок не только на иностранном языке, но и оставлять место для родного языка. Это увеличивает вероятность полного усвоения содержания урока всеми учениками.

При обучении геометрическому дискурсу на английском языке особую роль играет правильно подобранная стратегия использования иностранного и родного языков. Доминирующей стороной должен быть иностранный язык, так как чем больше учащиеся слышат информацию на английском, тем больше развивается бессознательное запоминание. Однако сознательное запоминание также важно, и его можно развивать путем многократного повторения одной и той же информации.

Помимо теоретических знаний, обучение геометрическому дискурсу на английском языке подразумевает развитие практических навыков. Учащиеся должны уметь формулировать свои мысли на английском языке, используя геометрические термины и понятия. Для этого необходимо предоставить им возможности для устной и

письменной практики, такие как обсуждение геометрических теорем, решение задач и выполнение проектов.

Кроме того, важно учитывать экстралингвистический контекст при обучении геометрическому дискурсу на английском языке. Это означает, что необходимо учитывать культурные и социальные особенности, связанные с изучаемой геометрической тематикой. Такой подход позволяет сделать обучение более эффективным и увлекательным для учащихся.

Таким образом, обучение геометрическому дискурсу на английском языке является сложным и многогранным процессом, который требует от учителя тщательной подготовки и использования различных методических приемов. Однако при правильной организации обучения учащиеся могут не только освоить геометрические понятия и термины на английском языке, но и развить свои коммуникативные навыки и расширить свой кругозор.

**Литература**

1. Амерханова О. О. Формирование дискурсивной компетенции в целях обучения иностранному языку.// Российская академия народного хозяйства и государственной службы при Президенте Российской Федерации. – 2016. – С. 216-220. URL: https://tmhe.spbstu.ru/userfiles/files/VMP19-2-216-221.pdf

2. .Митчел Л. А.,.Шильнов А. Г. Дискурс как основа формирования грамматических навыков в обучении иноязычному общению.// Журнал “Core”. – 2014. – С. 146-149/ URL: https://core.ac.uk/display/287460088?utm_source=pdf&utm_medium=banner&utm_campaign=pdf-decoration-v1

3. Русакова О.Ф. Основные теоретико-методологические подходы к интерпретации дискурса // Научный ежегодник ИФиП УрО РАН. – 2007. – №7. – С.5-34.

ЛЕКСИКАГА ӨЙРӘТҮДӘ СҮЗЛЕКЛӘРНЕҢ РОЛЕ

*Фатыйхова Л., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Галиуллина Г.Р.*

Мәгълүм булганча, телләрне укытуның нәтиҗәлелеген тәэмин итүдә һәм уңай шартлар тудыруга этәргеч бирүче мөһим элементлар арасында төп урыннарның берсе укыту чаралары алып тора. Татар телен укыту тәҗрибәсендә кулланылган укыту чараларының саны һәм характеры аларның төрле формада булуын күрсәтә. Укыту чаралары укучыларга яңа материалны кабул иткәндә, аны истә калдырганда, тиешле күнекмәләр формалаштырганда ярдәмче ролен үти. Ә белем бирү автономиясе (ягъни укучының үз эшчәнлегенә дөрес максатлар кую, үз эшчәнлеген планлаштыра белү, эш төрләрен сайлау, нәтиҗәгә ирешү сәләте) материалны ничек өйрәнергә кирәклеген генә түгел, ә үз максатыңа ирешү өчен нәрсәне һәм кайчан өйрәтергә кирәклеген дә сайлау мөмкинлеген бирә.

Чит телне үзләштерүдә лексика мөһим роль уйный. Нинди дә булса телдәге сүзләр җыелмасы лексиканы тәшкил итә. Лексика телдән аралашуының төп компоненты буларак, сөйләмдә грамматика һәм фонетика белән үзара бәйләнештә тора. Лексика ярдәмендә кешенең фикерләрен һәм хисләрен ачыкларга, шулай ук башкаларга тапшырырга мөмкин. Лексика үзе система рәвешендә үзләштерелергә тиеш, бу кешенең баш миенең логик яктан оешкан материалны истә калдыру, анализлау, синтезлау һәм гомумиләштерү үзлекләре белән бәйле [1: 326-328]. Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, телнең сүзлек ягын ныклы рәвештә үзләштерүнең зарурлыгы алгы планга баса, ул сүзлек өстендә эшләүне күз уңында тота.

Туган тел дәресләрендә сүзлекләр белән эшләү укучыларның сүзлек запасын баетуга юнәлдерелгән. Даими рәвештә сүзлекләр белән эш иткәндә, укучының теле шомара, сүз байлыгы арта. Шуңа күрә укучыларны телне үзләштерү өчен сүзлекләр кулланырга өйрәтү бик мөһим. Сүзлек белән эшләү укучыларда сөйләм эшчәнлеге өчен кирәкле сүзләрне мөстәкыйль һәм иҗади рәвештә эзләү ихтыяҗын тудыра һәм өйрәнелә торган телнең лексик байлыгы турындагы мәгълүматны шактый киңәйтә. Шулай ук бу укучылар башкара торган эшчәнлекнең индивидуальләштерелгән һәм мөстәкыйль төре, бу эшнең максаты – укучыларның сүзлек запасын системалы рәвештә тулыландыру [2: 88].

Сүзлек – сүзләрнең, тотрыклы сүзтезмәләрнең аңлатмаларын, мәгънәләрен, башка телгә тәрҗемәләрен һ.б.ш.ны җыеп, алфавит тәртибе белән яки бүтәнчә урнаштырып биргән белешмәлек, китап [3:

367]. Хәзерге тормышта сүзлекләрнең роле зур. Барлык сүзлекләрнең дә гомуми функциясе – белемнәрне ныгыту, системалаштыру, туплау һәм саклау. Татар телендә күптөрле сүзлекләр бар: тәрҗемә сүзлекләре, монолингвистик сүзлекләр, техник һәм махсус сүзлекләр һ.б. Сүзлекләр белән эшли башлаганда туган тел дәресләрендә ике телле тәрҗемә сүзлекләре белән эш итүнең төп принциплары алгы планга чыга, алардан башка телләрне өйрәнү мөмкин түгел. Бигрәк тә текстларны уку һәм тәрҗемә итү турында сүз барганда сүзлек белән эшли белү бик мөһим. Шулай ук сүзлектән кирәкле лексик берәмлекне тиз эзләү сәләтен үстерү дә зарур. Шуңа күрә сүзлек белән эшләүнең нәтиҗәлелеге укучының татар алфавитын ни дәрәҗәдә белүенә бәйле. Алфавит белән укучылар туган телне өйрәнүнең беренче елында ук таныша.

Чит телне өйрәнүчеләрнең күпчелеге хәтта ике телле сүзлекләрне дә нәтиҗәле укыту чарасы итеп кабул итми. Алар сүзлекне телне үзләштерү дәрәҗәсен күтәрү чарасы итеп түгел, ә бәлки сүз мәгънәләрен саклау чарасы дип саный. Шул ук вакытта, тиешле күнекмәләрне формалаштыру сүзлекләр кулланудан башка мөмкин түгел икәнлеген дә аңларга кирәк. Төрле сүзлекләр белән эшләү осталыгының югары дәрәҗәдә булуы тел үзләштерү процессында гына түгел, ә шул исәптән, катлаулылыгы буенча төрле коммуникатив, академик яки һөнәри мәсьәләләрне хәл итү өчен дә файдалы булырга мөмкин [4: 209].

Туган тел укытучысының бурычы – укучыларда дәресләрдә дә, биремнәрне мөстәкыйль рәвештә үтәгәндә дә сүзлекләргә даими мөрәҗәгать итү ихтыяҗын булдыру. Шул ук вакытта, тәҗрибәдә сүзлекләрнең хәзерге вакытта да мәҗбүри уку материалы буларак кабул ителмәвен дә әйтергә кирәк. Сүзлек белән эшләү үзләштерелә торган лексиканы системалаштыруга һәм аны телдән һәм язма сөйләмдә актив куллануга юнәлдерелгән булырга тиеш. Сүзлек белән эшләгәндә, аларның төрләре мөһим роль уйный.

Сүзлек эшенең хәзерге үсеш этабында күп кенә сүзлек жанрлары үзгәреш кичерә һәм аларның белем бирүгә булган йогынтысы көчәйтелә. Мәсәлән, уку сүзлеге белешмә материал буларак кына түгел, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үстерү һәм коммуникатив компетенция формалаштыру буенча мөстәкыйль уку әсбабы буларак та кулланылырга мөмкин. Телне камил рәвештә белүгә укучыларның тиешле әзерлеге булганда гына ирешергә мөмкин, ягъни аларны сүзлектән файдаланырга, сүзлекләрнең структурасын һәм төрләрен белергә өйрәтергә кирәк дигән сүз [4: 473].

Шуны истә тоту кирәк: дәреслекләрдә дә сүзлек белән эшләүгә

бәйле биремнәр тәкъдим итү максатка ярашлы. Тәкъдим ителгән биремнәр дәрестә һәм мөстәкыйль эш барышында сүзлекләрне тулы дәрәҗәдә куллану мөмкинлеген тудырмый. Сүзлекләргә нигезләнеп башкара торган биремнәр һәм күнегүләр төрле булырга мөмкин, ләкин бу биремнәрнең бүленешен дөрес тәэмин итү кирәк. Сүзлекләрдән дөрес файдалану – катлаулы күренеш, шуңа күрә әлеге күнекмәне даими рәвештә үстерү һәм формалаштыру зарур.

Шулай итеп, укучылар тел өйрәнү барышында төрле сүзлекләр белән танышып кына калмый, ә бәлки аларны дөрес итеп кулланырга да өйрәнә. Моның нәтиҗәсендә, сөйләмдә очрый торган хаталар кими, сүзлекләр ярдәмендә укучы төрле кимчелекләрен бетерә ала. Укытуның төп бурычы “укыту” гына түгел, ә бәлки “укырга” һәм “уйларга” сәләтле бәйсез шәхесләр тәрбияләү дә. Сүзлекләр белән дөрес эшләү нәтиҗәсендә моңа тиз вакыт аралыгында ирешергә була.

**Әдәбият**

1. Бутаев Ш.Т. О методике совершенствования работы со словарем // Молодой ученый. – 2012. – № 10. – С. 326-328.

2. Кузин В.С. Психология. – М.: Высшая школа, 1982. – 256 с.

3. Потиха З.А., Розенталь Д.Э. Лингвистические словари и работа с ними. – М.: Просвещение, 1987. – 88 с.

4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: V том: С – Т. – Казан: ТӘһСИ, 2019. – 908 б.

# ТАТАР ПАРЕМИЯЛӘРЕНДӘ ЯШЬ ФӘЛСӘФӘСЕ

*Фатыхова А., КФУ, I курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. док., доц. Юсупов А.Ф.*

Татар паремияләрендә яшь фәлсәфәсе кеше тормышының балачак, яшьлек һәм картлык этапларына нисбәтле рәвештә ачыла. Әйтик, яшьлек картлыкта булмаган зур мөмкинлекләр (көч, сәламәтлек) белән характерлана, әмма яшьлек бер төркем проблемаларга да ия (тормыш тәҗрибәсе булмау). Татар халкында яшьлек тәмамлану һәм картлык башлану яшенә карата түбәндәге мәкаль яшәп килә: Кырыкка кадәр малай, кырыктан соң бабай [5].

Безнең фикеребезчә, әлеге мәкаль өлкән яшьтәге кешенең типик хәл-әхвәленә, кәефенә карата реакция булып тора һәм билгеле бер дәрәҗәдә ул медицина өлкәсендәге белгечләрнең фикере белән туры килә, чөнки "Гиппократ вакытында кырык яшьне – яшьлектән картлыкка күчеш яше дип санаганнар", ә бүген Бөтендөнья сәламәтлекне саклау оешмасы яшь дип 25 яшьтән 44 яшькә кадәр кешене саный [1].

Татар паремияләренә үткәргән күзәтүебез шуны күрсәтә: биредә үсмерлек яше аерып каралмый, кеше "бала" булудан соң ук "яшьлек" чорына күчә. XX гасыр башына кадәр үсмерлек яшенең булмавының аңлатмасы бар: балалар бик тиз олылар рәтенә күчкән. Галимнәр патша Россиясе турында болай дип яза: "традицион рәвештә җитлегү яше булып унбиш яшь тора: нәкъ менә унбиш яше тулу белән морза улы ат, кылыч, утарга ия булган һәм сугышка бара алган. Бу башка катлау кешеләре өчен дә характерлы: ундүрт – унбиш яшькә җиткән крестьян улы яки кызы тәмам зур кеше булып саналган, саналган гына түгел, зур кеше булып торган, ягъни алар үзләрен үз хезмәтләре, шул исәптән, ялланып эшләү белән тәэмин итә алган. Кайбер крестьяннар арасында ун яшьлек малайлар ук "эшкә яраклы" саналган һәм алар гаиләләреннән аерылып заводларга һәм рудникларга эшкә чыгып киткән" [8]. Бу үзенчәлек татар паремияләрендә дә күзәтелә. Мәсәлән, түбәндәге паремиядә бәхетле ата-ананың баласы инде унбиш яшьтә үк тулыканлы өлкән кеше булып тору, һәм киресенчә, утыз яшьтә дә үзен бала кебек тоткан һәм ата-анадан аерыла алмаган кешенең ата-анасы бәхетсез булу турында искәртелә: Бәхетленең баласы унбишендә баш булыр, Бәхетсезнең баласы утызда да яшь булыр [3: 13].

Түбәндәге паремиядә өлкәнәюнең яшь кысалары тагын да киметелә: Булыр бала ун яшендә баш була, Булмас бала егерме биштә дә яшь була [3: 13].

Паремияләрдә картлык җитү белән тормышның сыйфаты начараю турында хәбәр ителә, аерым очракларда моның вакыты, яше төгәлләштерелә. Мисал өчен: Яшең җитсә кырыкка, эшең китә шырыкка [5].

Кайбер мәкальләрдә балачак һәм картлыкның үзара бәйләнеше ассызыклана. Әлеге яшь этапларының уртак үзлек-хасиятләре түбәндәге паремиядә чагылыш таба: Алтыдагы – алтмышта [6].

Картлык турындагы мәкальләрдә яшь барган саен кешенең тышкы кыяфәте үзгәрү, хәтере, фикер йөртү тизлеге начарлану турында гына түгел, ә социаль күнекмәләр дә начар якка үзгәрү искәртелә, ягъни карт кеше мыгырдаучан, сукранучанга әйләнә. Татар халкы бу үзенчәлекләрне дә паремиологик фондта чагылдырган: Яше күп тә акылы юк [6].

Кайбер мәкальләрдә картлыкта да акыл һәм йөрәкне яшь килеш саклау, ягъни бөтен яңачалыкка ачык булу әһәмияте турында ассызыклана: Башың карт булса да, йөрәгең яшь булсын [7: 128], Акыл яшьтә түгел, башта [6].

Алга таба картлык кешенең Җирдә яшәвенең мөһим этабы буларак характерланган паремияләрне карап үтик. Моның турында фәлсәфәче Г. Гессе шактый кызыклы яза: “Карт булу – яшь булу төсле үк шәп һәм кирәкле бурыч, үләргә өйрәнү һәм үлү – теләсә-кайсы башка вазифа төсле үк мөхтәрәм вазифа. Картлыктан, чал чәчтән һәм үлемнең якынаюыннан курыккан һәм аңа нәфрәтле булган карт кеше, үзенең эшен һәм көндәлек хезмәтне күралмаган һәм аннан качарга тырышкан яшь һәм көчле кеше кебек үк, үз яшь этабының ихтирамга лаек булмаган вәкиле” [2: 203]. Безнең тарафтан өйрәнелгән татар паремияләрендә, картлыкка карата мондый фәлсәфи мөнәсәбәт берникадәр дәрәҗәдә түбәндәге паремиядә чагылыш таба: Яшен яшәгән, ашын ашаган [3].

Нәтиҗәгә килеп фәлсәфәче С. Лишаев сүзләрен әйтергә кирәк: “яшь ул – мөмкинлекләр дә, проблемалар да” [4]. Әлеге фикер белән килешми мөмкин түгел, бит халык та паремияләрендә шушы ук фикерне белдерә.

**Әдәбият**


1. Возрастная классификация ВОЗ. – URL: https://agesecrets.ru/vozrast/vozrastnaya-klassifikatsiya-vsemirnoj-organizatsiizdravo ohraneniya (Дата обращения: 18.01.2024).
2. Гессе Г. О старости // Развитие личности. – 2017. – №4. – С. 203-206.
3. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Яр Чаллы: “Идел-йорт”, 2003. – 100 б.

4. Лишаев С. Философия возраста (возраст и время). – СПб.: Алетейя, 2022. – 512 с.
5. Татар мәкальләре. – URL: https://tt.wikibooks.org/wiki/ (Дата обращения: 18.01.2024).
6. Татарча мәкальләр. URL: http://proekts.maratkabirov.com /tostlar/tatarcha_mekeller.html (Дата обращения: 18.01.2024).
7. Татарча мәкальләр һәм әйтемнәр / төз. Р.Ахмадишина. Электрон китап. Litres, 2022. – 158 б.
8. Шипилов А.В. “Старость” в прошлом и настоящем: – URL: https:// cyberleninka.ru/article/n/starost-v-proshlom-i-nastoyaschem; дата обращения: 18.01.2024.

# ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ
#ҺӘМ ИҖАТЫНА КҮЗӘТҮ

*Фәтхетдинова С., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гайнуллина Г.Р.*

«Каләм иясе үзенә кирәк материалны каян ала соң? Болар – шәхси биография, ишеткән-белгәннәр һәм фантазия! Менә шулар өчесе бергә кушылып киткәннән соң әдәбият дигән могҗиза барлыкка килә дә инде» [1: 124] – ди Рашат Низами. Авторының биографиясенә мөрәҗәгать итү язучының дөньяга карашын, аңларга, гомүмән, әсәрне тулырак анализларга ярдәм итә.

Күренекле шагыйрь, язучы-прозаик, драматург Фәнис Гатаулла улы Яруллин (паспорт буенча Фаниз Яруллин) 1938 елның 9 февралендә Татарстанның Баулы районы Кызылъяр авылында игенче гаиләсендә доньяга килә. Ул Кызылъярның җидееллык мәктәбен тәмамлый, аннары бер ел район үзәге Баулыдагы урта мәктәпнең сигезенче сыйныфында укый.

1957 елда Армия сафлыгына алына, һава укчы радистлар мәктәбендә укый. Ул спорт белән мавыга, күнегүләрнең берсендә, тукниктан егылып төшеп, умыртка сөяген имгәтә һәм гомерлек йөри алмаслык хәлдә кала.

Озак еллар хастаханәләрдә даваланып ятуына карамастан, Фәнис бөтен игътибарын белем дәрәҗәсен күтәрүгә, әдәби иҗат эшен үстерүгә юнәлтә: 1963 елда урта мәктәп программасы буенча экстерн рәвешендә имтихан бирә һәм таныклык ала, 1964-1970 елларда Казан дәүләт университетында читтән торып укып, тарих-филология факультетының “Татар теле һәм әдәбияты укытучысы” дигән белгечлек ала. Шул елларда ул иҗатка кереп китә.

1964 елда, Татарстан китап нәшриятендә беренче мөстәкыйль китабы – “Мин тормышка гашыйк” исемле шигырьләр җыентыгы чыга. Шул ук елда “Комсомольская правда” газетасы яшь шагыйрьләрнең Ботенсоюз конкурсын оештыра, аның бер өлеш шигырьләре 2 дәрәҗәге бүләккә лаек була һәм, рус теленә тәрҗемә ителеп, “Розовый олень” исемле күмәк җыентыкка кертелә. Бу конкурс аның исемен бөтен Союз укучыларына тарату өчен тәэсир ясый.

1968 елда Фәнис Яруллин СССР Язучылар союзына әгъза итеп алына. “Бакчалар бәскә төренә” (1967), “Минем елмаю” (1968) дигән шигырьләре чыга. Әсәрләре “Литературная Россия”, “Современник”, “Аврора”, “Волга”, “Огонек” кебек газета-журналларда басыла.

Фәнис Яруллинның “алга юллар салышучыларның” берсе булып– Фазлыян кызы Нурсөя тора. Казан шәһәренең 18нче кичке

мәктәбендә укыганда танышалар һәм биш елдан соң никахлашалар. Аның әсәрләре басылуында ул зур роль уйный: шигырьләрен кәгазь битенә тезә, гәҗит-журналларга итә. 2006нчы елда Фәнис Яруллин хатынына багышлап "Нурсөя" поэмасын яза.

Аның иҗаты турында күп кенә язучылар үз фикерләрен белдерәләр. "Фәнис Яруллинның шигырьләре үзләренең ихласлыгы, уйчан лиризмы, үзләренәгенә хас эчкерсезлеге белән аерылып тора һәм аны кабатлап та булмый" [2: 184]. Марс Шабаев шигъри стилен бәяли: "Шагыйрьнең шигъри стиле, образлар системасы хакында озаклап,тәфсилләп сөйләргә булыр иде. Шунысын гына ассызыклап үтәргә кирәк:Фәнис Яруллин гади яза, халыкчан яза. Шагыйрь, классик поэзия тарафдары [3: 3].

Алтмышынчы-җитмешенче елларда яшүсмерләр өчен проза әсәрләре туплаган җыентыклары нәшер ителә: «Май төне» (1966), «Ачсаң күңел тәрәзәләрен» (1969), «Яшел утрау хуҗалары» (1976). Җитмешенче елларда ул проза жанрының зуррак формаларына мөрәҗәгать итә. 1971 нче елда «Җилкәннәр җилдә сынала» повестен яза. Проза әсәрләре тематикасы: иҗтимагый тормышның җитешсез якларын тәнкыйтьләү – «Һәркемнең үз сукмагы» (1982), «Туган көн бүләге» (1984), «Урман кызы» (1998) хикәяләр җыентыклары; хәзерге заман хатын-кызы – «Кыйгак, кыйгак каз кычкыра» (1994), «Бүләк» (1999), «Портрет» (2000) повестьлары; балалар йортында тәрбияләнүче балаларның язмышлары – «Яралы язмышлар» (2000) повесте. Әсәрләре инглиз, венгер, каракалпак, башкорт, азәрбайҗай, молдован телләренә тәрҗемә ителә.

Авторның Татарстан һәм Башкортстан театрларында сәхнәләштерелгән әсәрләре бар. Драматург иҗат иткән пьесаларның бер өлеше аның «Таң вакыты» (1969) һәм «Пьесалар» (1998) исемле тупланмаларында урын ала.

Туксанынчы елларда ил иҗтимагый төзелеш ягыннан зур үзгәрешләр кичерә. Бу елда язылган әсәрләре түбәндәге проблемаларны актуальләштерә: шәхес иреге һәм кеше хокуклары («Өзелгән өмет»), кеше һәм җәмгыять арасындагы катлаулы мөнәсәбәт («Урман кызы», «Тәрәзәгә кунган күбәләк»).

Чәчмә формадагы әкиятләрен дә шигъри телдә яза. Аның әкиятләре төрле темага карый: максатка ирешү "Алсу чәчәк" (1993), әхлакый батырлык. "Яралы торна" (1996), "Кыядагы ояда" (1997), экологиягә кагылышлы "Хәзинә", "Хәким карт урманы" (1987), хәтер калдыру "Тылсымлы ачкыч", яхшылык кылу "Рәссам кызы", "Кызыл алма".

Фәнис Яруллин публицистика юнәлешендә дә эшли. 1997 елны “Көн сулышы: мәкаләләр, очерклар, рецензияләр” китабын бастыра. 2000нче елларда “Сөенечләр бүлешү” эссесы “Мәгариф” һәм “Мәйдан” журналында басыла.

1978 елда “Аерылмас дустым” һәм “Сулыш” исемле шигырь китаплары өчен Фәнис Яруллин “Татарстанның Муса Җәлил бүләге лауреаты” дигән мактаулы исем бирелә. 1985 елда “Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре”. 1988 елда “Халыклар дуслыгы” ордены. 1995 елда исә ул “Җан авазы” дигән китабы өчен Татарстан Җөмһүриятенең Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләген ала. 2001 елда Татарстан Президенты М.Ш. Шәймиев Указы белән “Татарстан Республикасының халык шагыйре” дигән мактаулы исем бирелә.

Фәнис Яруллин 2011 елның 8 декабрендә Казанда вафат була. 2021нче елны Казанда Жуковский урамы 9 йорт диварында Фәнис Яруллин истәлегенә мемориаль такта ачыла. 2010нчы елны Татарстанның Баулы районы Кызылъяр авылында Яруллинның исемен мәңгеләштерү максатыннан музей ачыла.

**Әдәбият**

1. Низами Р.М. Каләм алдым кулыма... // Казан утлары. – 2006. – №1. – Б. 120 – 141.

2. Зөлфәт. Минем елмаю // Казан утлары. – 1969. – № 2. – Б.184-185.

3. Яруллин Ф. Безнең яраткан әдипләребез / Сабантуй. – 1995. – 12 апр.

